Ий, төәминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның динена нык тотып ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!
(Коръәни-Кәрим, 3:103.)

ДИН Һәм Мәгыйшәт

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ • №2 (223) ФЕВРАЛЬ 2014 / РАҺИГЫЛЬ-АХЫР 1435

"ДИН ГЫЙЛЕМГӘ, ГАМӘЛГӘ Һәм ИХЛАСЛЫККА НИГЕЗЛӘНӘ"

2 нче бит

"КУКМАРА ИШАННАРЫ" БУЛДЫРДЫ

2 нче бит

ДИНИ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРНЕ ТОРГЫЗУ ЕЛЫ

Әссәләәму галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ!

Мөхтәрәм дин кардәшләребез!

Гасырлар дәвамында татарлар ислам динен тоткан. Элекке чорлардан алып безнең көннәргә кадәр Коръәнгә һәм Сөннәткә берничек тә каршы килми торган горефгадәтләрне үтәү үзенчәлекләре барлыкка килгән. Күренекле дин эшлеклеләребез Шиһабетдин Мәрҗани, Габдерәхим Утыз Имәни, Габденнасыйр Курсави һәм башкалар күпләгән фундаменталь хезмәтләр язган. Безнең бурыч - аларны саклау. Әмма ислам дине яшәештә үзеңә бикләнгәнлекне кабул итми генә түгел, һәрбер мөселманнан белемнәре белән бүлешүне дә таләп итә. Аллаһның Илчесе (с.г.в.) болай дигән: "Кеше вафат булгач, өч әйбердән кала аның барлык гамәлләре дә өзелә: туктаусыз килеп тора торган сәдака, (башка кешеләр) файдалана ала торган белем, яки әти-әнисе өчен Аллаһка дога белән мөрәҗәгать итәчәк турылыклы баласы булу" (хәдис Мөслимнән китерелә). Кеше калдыра торган белемнәр - Кыямәткә чаклы даими килеп торачак саваплар чыганагы ул.

Бабаларыбызга хәтта дин кысылган елларда да Идел буе болгарлары ислам динен кабул иткәннән бирле безнең җирлектә урнашып килгән дини мирасны саклап калу насыйп була.

Бүген безнең бурычыбыз - кайсыдыр дәвердә җуелган, онытылган, югалганнарны торгызу. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең дини китапларны нәшер итүгә һәм кайберләрен кабаттан бастыруга аерым игътибар бирүе очраклы түгел. Соңгы бер-ике елда дип әйтсәк тә була, ислам дине турында белергә теләгәннәргә һәм үзләренең белемнәрен тагын да тирәнәйтергә теләгәннәр өчен дә китаплар басылды. Бу эшләребезнең киләчәктә дә дәвамлы булуын Аллаһ Раббыбыз насыйп итсә иде. Аллаһы Тәгалә безгә Коръәннең хакыйкый булуын сакларга вәгъдә бирә. Без исә ислам динен сакларга һәм таратырга тиеш.

Мәчетләрне саклау һәм торгызу мәсьәләсе һаман да көн кадагында кала бирә. Без бүген мәчетләрне җимерелүдән түгел, ә бәлки юньсезлектән, фетнәдән һәм бушап калудан сакларга тиеш. Аллаһ йортлары буш торырга тиеш түгел. Ишекләрне йозаклар асып куелган хәлдә тотарга ярамый. Без мәчетләрне Аллаһка гыйбадәт кылу урыны буларак кына түгел, динебезне өйрәтү, мөселманнарның проблемаларын хәл итү урыны буларак та сакларга тиеш. Республикабызда кайчандыр җимерелгән дини биналарны кайтару эше дәвам итә - бу шулай ук татар мөселманнарының дини мирасын торгызу буенча эшләнә торган зур эшләрнең бер өлеше.

Диния нәзарәте 2014 нче елны Дини гореф-гадәтләрне торгызу елы дип игълан итте. Бу елыбыз соңгы елларда алып барылган эшчәнлегебезне дәвам итәчәк. Бик күп чаралар үткәрелгән, шул исәптән Коръәннең данлыклы "Казан басмасы" нәшер ителгән Коръән елы инде күптән узып китте. Узган ел Шиһабетдин Мәрҗани елы булган иде. Әлбәттә, нинди дә булса Ел игълан итү - гореф-гадәтләрне торгызу һәм мирасыбызны саклау мәсьәләләренә тагын да күбрәк игътибар биреләчәген генә аңлата. Динне саклау - һәрбер мөселманның көн саен үтәлергә тиешле изге бурычы ул. Һәр кич саен без үзүзебезгә сорау бирергә тиеш: мин бүген Аллаһы Тәгалә барлык мөселманнарга һәм минем хакка Кыямәт көненә кадәр сакларга вәгъдә биргән дин өчен нәрсә эшләдем?

Татарстан Республикасы мөфтие
Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН

БҮГЕНГЕ САНДА:



ГАЛИМ ИЛЕНӘ КАЙТТЫ

Согуд Гарәбстанына сәфәре вакытында мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Япония мөселманнары лидеры, доктор Салих Мәһди әс-Сәмараи белән очрашты. Япония мөселманнары лидеры Камил хәзрәткә Японияга беренче булып ислам динен китереп җиткергән һәм халык арасында аны таратуны башлап җибәргән XX гасыр башы татар галиме, тарихчы, вагыйз Габдерәшит Ибраһимов турындагы фәнни хезмәтен бүләк итте.

8 нче бит

МАТУР БУЛУНЫҢ ҖИДЕ СЕРЕ

13 нче бит

ГАЗЕТАДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ ИСЕМНӘРЕ, КОРЪӘННӘН АЯТЬЛӘР БАР, АНЫ ТИЕШСЕЗ УРЫНГА КУЛЛАНУДАН САКЛАНЫГЫЗ!

Вәлиулла хәзрәт эше дәвам иттереләчәк

Апанай мәчетендә мөфти урынбасары, мәчетнең имам-хатыйбы Нияз хәзрәт Сабиров журналистларны, кунакларны мәхәлләдә һәм "Иман" нәшриятында алып барылган эшчәнлек белән таныштырды. Чарада шулай ук мөфти урынбасары Илдар хәзрәт Баязитов, РИИ ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин, Казан мөхтәсибе Мансур хәзрәт Җәләлетдинов һәм мәхәллә картлары катнашты.

Белгәнебезчә, күп еллар дәвамында әлеге мәчетне, мәхәлләне, нәшриятны 2012 нче елда фаҗигале төстә арабыздан киткән танылган дин әһеле Вәлиулла хәзрәт Якупов җитәкләде. Мөхтәрәм хәзрәтләребез Вәлиулла хәзрәтнең динебезне таратуга һәм тарихи мәчетне торгызуга керткән өлешен югары бәяләп искә алдылар. Бүгенге көндә Апанай мәчетен Вәлиулла хәзрәтнең шәкерте, ул чыгарган газеталарга мәкаләләр язган һәм мәчет эшчәнлеген алып баруда булышлык иткән Нияз хәзрәт Сабиров җитәкли. Хәзрәт үзенең чыгышында "Иман" нәшриятының эше дәвам иттерелүен ассызыклады. Ул "Иман" нәшрияты бер айда чыгарган китапларны тәкъдим итте. Бүгенге көндә мәчеттә оештырылган укулар хакында да сүз булды. Биредә Коръән уку һәм ислам хокукы буенча дәресләр уздырыла. Нияз хәзрәт Вәлиулла хәзрәткә багышланган музейның баетылуы һәм аны тәртиптә тоту буенча чаралар күрелүе хакында сөйләде. Моннан тыш мәчеттә мәҗлесләр уздыру һәм дәресләр үткәрү бүлмәсен төзекләндерү эшләре планлаштырыла.

"Кукмара ишаннары" булдырды!

Ватанны саклаучылар көнендә Кукмара мәдрәсәсендә "Мөслимнәр бәйгесе" уздырылды. Әлеге чараны Татарстан мөселманнары Дания нәзарәте белән бергәлектә мәдрәсә коллективы оештырды. Бәйгедә биш кешедән торган дүрт команда - "Яшел түбәтәйләр", "Ак чалмалар", "Ислам баганалары" һәм "Кукмара ишаннары" - катнашты. Алар үзләре белән матур итеп таныштырудан тыш азан әйттеләр, Коръән укыдылар, вәгазь сөйләделәр, викторина сорауларына җавап бирделәр. Шулай ук дартс уенында, гер күтәрүдә, хәтта салат әзерләүдә осталыкларын күрсәтергә туры килде. Берничә ел рәттән уздырылып килгән чараның быелгысында "Кукмара ишаннары" командасы җиңде. Жюри әгъзалары бәйгенең оештырылуына югары бәя бирде.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН:

"ДИН ГЫЙЛЕМГӘ, ГАМӘЛГӘ ҺӘМ ИХЛАСЛЫККА НИГЕЗЛӘНӘ"

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин нәзарәтнең быелгы эшчәнлеге белән таныштыру, Согуд Гарәбстанына сәфәре турында сөйләү һәм республика мөселманнарына кагылышлы сорауларга җавап бирү максатыннан журналистлар белән очрашты. Мөфти белән җылы әңгәмә Кол Шәриф мәчетендә чәй өстәле артында барды. Чарада мөфтинең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батыр, "Хузур" нәшрият йорты директоры Ришат Хәмидуллин катнашты.

Камил хәзрәт сөйләшүне Коръән сүзләре белән башлап җибәрде. Аннары ул сәфәр хакында кыскача сөйләп узды. "Февральдә Согуд Гарәбстанына бик зур сәфәр кылынды. Бу сәфәр ике өлештән торды. Бердән, безне анда Согуд ГарәбстаныныңМәскәүдәге илчелеге чакырды. Икенчедән, Россиянең хаҗ миссиясе делегациясе эшендә катнаштык. Гарәбстанда төрле җитәкчеләр, галимнәр белән аралаштык. Гарәп галимнәренә зур горурлык белән үзебездә чыккан китапларны бүләк итеп калдырдым. Сәфәрнең икенче өлеше хаҗ эшләренә багышланды. Беренче тапкыр Гарәбстанның хаҗ министры Россия делегациясе белән очрашты. Без хаҗга квоталарны киметмәүне сорадык. Алар әлегә каршы килмәде", - диде.

Нәзарәт эшчәнлеге турында сөйләгәндә мөфти: "Безнең төп ниятебез мәгърифәтчелекне һәм социаль эшләрне тагын да ныгыту һәм ислам имиджын үстерү, - дип ассызыклады. - Аллага шөкер, 2014 ел бик күркәм бәйрәмнән башланып китте. Гыйнвар аенда авылларда Пәйгамбәребезне (с.г.в.) зурлаган Мәүлид бәйрәмнәре узды. Беренче мәртәбә Россия күләмендә имамнар Болгарга Мәүлидкә җыелды. Бабаларыбыз Пәйгамбәрне (с.г.в.) ничек олылаган, менә шуның үрнәге күрсәтелде. Авыллардагы имамнардан башлап, шәкертләргә кадәр, татар халкының дини мирасын, гореф-гадәтләрне белергә, аңларга тиешле дигән максаттан мөфтият тарафыннан бу ел "Дини гореф-гадәтләребезне торгызу елы" дип игълан ителде.

Агымдагы елда "Ел имамы" конкурсы уздырыла. Мөхтәсибләр үз районнарыннан берәр имамны тәкъдим итәчәк. Шуннан соң смс-хәбәрләр аша "Иң яхшы имам"ны ачыклау каралган.

Мәдрәсәләрнең укыту программасына кертелгән 30 дәреслек әзерләнә. Дәреслекләр баларыбыз гыйлем алган китаплардан гыйбарәт.

Әгәр күңелне иман, гыйлем белән тутырмасак, безнең башны кирәкмәгән мәгълүматлар белән тутырачаклар. Башта һәр мөселман белергә тиешле бурычларны, ягъни минимум гыйлемне өйрәнергә кирәк. Шулай ук үзебезнең мәдәниятне, мирасны белик һәм шуларны саклыйк. Болар безгә эчәр суыбыз, ашар ризыгыбыз, сулар һавабыз кебек үк кирәк. Тагын ихлас гамәлләр кылыйк. Дин өч әйбергә таяна - гыйлем, гамәл һәм ихласлык", - диде Татарстан мөфтие.

2013 нче елда ачылган "Хузур" нәшрият йорты китаплар бастыру, дини сайтлар эшләтү белән шөгыльләнә. Чарада "Хузур"ның яңа проекты - "Әбу Хәнифә" дип аталган беренче аудио-китабы тәкъдир ителде. Китап татар һәм рус телләрендә әзерләнгән.

Журналистлар мөфтигә күп сандагы сорауларын, тәкъдимнәрен һәм гозерләрен дә җиткерделәр. Нәзарәт тарафыннан уздырылып килә торган дини темага язучы журналистларның "Каләм" конкурсы янә игълан ителде. 2013 нче елның 1 нче апреленнән башлап 2014 нче елның апреленә кадәр дөнья күргән язмаларны 1 нче апрельгә кадәр нәзарәтнең матбугат үзәгенә тапшыру сорала.

Айзирәк ГӘРӘЕВА

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның Согуд Гарәбстанына кылган эшлекле сәфәре турындагы тулырак язманы газетабызның 8 нче битеннән укый аласыз.

Аллаһы Тәгалә безгә Коръәни-Кәрим аша әмер иткән фарыз гамәлләр ике төрле: фарыз гәйен һәм фарыз кифая. Фарыз кифая дигәнендә әмерне бер кеше үтәсә, гөнаһ башкалар өстеннән төшә. Менә яшь кенә бер егет имам булып авылга кайтты, ди. Эшли башлый бу, үзенчә тырыша, әлбәттә, анда хезмәт хакы юк, яшәү шартлары начар. Күпмедер вакыт интегеп яшәгәннән соң, Казангамы, башка шәһәргәме төзелешкә яки шабашкага китеп бара икән, бу бөтен авылга гөнаһ булып төшә. Чөнки авыл - мәхәллә фарыз кифаяне үтәп, бер имамны тота алмады.

МӘЧЕТ ИШЕГЕНӘ ЙОЗАК ЭЛЕНСӘ, ГӨНАҺЫСЫ - МӘХӘЛЛӘГӘ

Бу мисалны юкка гына китермәдем. Авылларда бик күп йөрибез. Кайсына гына килеп төшсәк тә, сүзне, хәзрәт, менә имамнарга зарплата, теге кирәк, бу кирәк, дип башлыйлар. Кайберәүләр имамнарга хезмәт хакын да, башкасын да Дания нәзарәте бирергә тиеш дип уйлый. Әлбәттә, мөфти хәзрәтебез, әлхәмдүлилләһ, яшь имамнарга авыр икәнне аңлый. Аларга төрле яктан ярдәм итәргә тырыша. Ләкин бу вазифа мөфти өстендә түгел, ул шушы имамнарны үз артыннан иертеп баручы. Сәләтле бер яшь егетне укытып кайтару, аны өйләндерү, ашатуэчертү шушы мәхәллә өстендә, авыл халкы (йөриме ул мәчеткә, йөрмиме) өстендә. Менә, иң мөһиме, шуны белергә кирәк. Әгәр дә мәчет ишегенә амбар йозагы эленгән икән, моның гөнаһысы бөтен авылга. Теге кирәк тә бу кирәк, дип таләп итеп, яки китереп биргәнне көтеп утырганчы, яшь хәзрәтнең өенә кереп, суыткычында ризыгы, базында бәрәңгесе бармы, бу егет ач яткыймы икән - шуны кара син. Әгәр мулланы читтән китерәсез икән, аны торак белән тәэмин итү мәсьәләсен дә кайгыртырга кирәк. Монысын инде мәхәллә хөкүмәт белән берләшеп кенә хәл итә ала.

Быелгы елга зур яңалыклар белән кердек. Яхшы яңалыклар күп, Аллага шөкер. Дания нәзарәте һәм мөфти хәзрәтебез тарафыннан күп мәсьәләләр хәл ителде. Шул ук яшь имамнарга, әгәр дә алар 3 елга хәтле авылда эшли икән, 180 мең сум күләмендә грантлар бирелә башлады. Бу авыл хәзрәте өчен бик зур акча. Минем бер үтенечем бар: бүгенге көндә мәдрәсәдә, ислам институтында мәхәлләгездән чыккан берәр егет укып ята икән, аны, авылга кайт, без диния нәзарәтенә язып сорарбыз, сиңа да, Алла боерса, мөфти хәзрәтебез грант бирер, дип авылыгызга кайтарыгыз.

Аннары, Аллаһы сүбханә вә Тәгалә көч-куәт биреп, зур проблемаларның берсен - газ мәсьәләсен хәл итеп бетерәсе бар. Хәзрәт, ярдәм ит, дип мөрәҗәгать итүчеләр булды. Бик зур счет килмәсен дип ягуны киметкәннәр дә, батареялар туңып, инде хәзер ягулык системасын ясарга кайдан акча алырга белмиләр. Бүген һәрбер мәхәллә, юридик зат буларак, газ яккан өчен ике мәртәбә күтәрелгән хак түли. Инде Мәскәүгә хатлар киткән, шушы мәсьәлә, иншә Алла, уңай хәл ителеп, мәчетләр гади халык кебек, 5 мең сум урынына ярты хакын гына түли башлар, дип өметләнеп торабыз.

Җайга саласы тагын бер эшебез бар әле, ул - никах уку, балага исем кушу мәсьәләсе. Менә бу эшләр имам-хатиплар тарафыннан башкарылсын иде. Соңгы вакытларда безне шундый хәл хафага сала башлады: кызларыбызны зурлап "әйбәт егет"кә кияүгә бирәбез, ахырдан аның икенче, өченче, дүртенче хатын булуы ачыклана. Кызганычка, моны бик тикшереп тә булмый. Шуңа күрә никахлар мөхтәсибәт аша теркәлсен иде, дигән теләк бар.

Аллага шөкер, муллаларга эшләр өчен хәзер мөмкинлекләр зур, чөнки күп мәсьәләләр хәл ителгән. Эшләрендә файдаланыр өчен "Шура" журналы чыгып килә, намаз вакытлары расланган. Инкыйлабка хәтле Дания нәзарәте тарафыннан имам-хатипларга, имамнарга, мөәзиннәргә шаһадәтнамә бирелә торган булган. Әлхәмдүлилләһи, ел дәвамында имамнарның белемен күтәрү буенча эш барды һәм шаһадәтнамәләр тапшырылды. Алла боерса, бу эш алга таба да дәвам итәчәк. Дания нәзарәтенең мөхтәсибләр, имамнар һәм мөәзиннәребезнең халык алдында абруйларын күтәрү теләге бар.

Рөстәм ХӘЙРУЛЛИН,
мөфти урынбасары

ТАТАР ХАЛКЫН ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ ЛИДЕРЫ ИТКӘН ӨЧ КИЛЕШҮ

Антонио Бандерас уйнаган "13-й воин" кинофильмын караганнар Идел буе җирләренә килеп җиткәч, аның героеның: "Кичләр монда күпкә озынрак", - дигән сүзләренә игътибар иттеләр микән? Ә бу сүзләр эчендә гасырлар буе килгән тулы бер тарих яшерелгән. Антонио Бандерас "13-й воин" кинофильмында борынгы болгарлар янына алар тоткан ислам диненә рәсми статус бирер өчен килгән Багдад илчелеге сәркатибе Әхмәд ибн Фадланны уйный. Бу 922 нче елның 21 нче маенда була.

Әхмәд ибн Фадлан үзенең Идел елгасына сәфәре турындагы атаклы язмаларында алда әйтеп үтелгән цитатаның мәгънәсен ачкан бер кызыклы вакыйганы сурәтли. Килгәннең беренче көнендә үк илче ахшам намазын укыганнан соң, азан ишетеп, ястү намазына чакыралар дип уйлый. Ләкин бу иртәнге намазга чакыру булып чыга. "Ә соңгы - ястү намазы?" - дип гаҗәпләнә кунак ястү намазына азан яңырамавына. Аңа: "Без ястү намазын кояш баеганда укыйбыз", - дип җавап бирәләр.

Башкача әйткәндә, борынгы бабаларыбыз ислам динен кабул иткәч, безнең җирлектә кайбер мәсьәләләрдә аның күрсәтмәләрен үтәү мөмкин түгеллеген күрәләр. Дин кануннары буенча бишенче намаз төнге караңгылык төшкәч үтәлә. Ләкин безнең җирлектә җәй көне кичке әңгер-меңгер әкрен генә шәфәкъ алсулыгына күчә. Ястү намазын бу очракта ничек укырга?

ХАКЫЙКАТЬ ТЕЛЕСКОПЫ АША

Бишенче намазны уку вакытын билгеләүгә һәм ислам динен рациональ яктан төшенү мәсьәләләренә татар дөньясының мәшһүр дин эшлеклеләре дә үз өлешләрен кертәләр. Бу темага Габдрахим Утыз-Имәни, Габденнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани дә аерым хезмәтләрен багышлый. Бу хезмәтләр татар халкы рухый мирасының алтын фондына керә.

Кызганыч, дәһрилек чорында татарларның дини-интеллектуаль фидакарьлеген дәвам итә алучыларны калдырмадылар. Ислам гореф-гадәтләрен саклап калырга тырышучылар репрессияләргә дучар булды, мәдрәсәләр, дини нәшриятлар ябылды, гарәп шрифты латинга алыштырылды һәм бу кешеләрне язма мирасыбыздан аеруга китерде. Болар берсе дә эзсез узмады. Җирлегебездә гасырлар буе сакланып килгән Пәйгамбәребез (с.г.в.) дине бозылу куркынычы яный башлады һәм бишенче намазны да урап узмады. Аның вакытын ничек туры килә, шулай исәпләделәр.

Нәкъ менә шуңа күрә бүгенге көндә мөселман өммәте алдында беренче чыганакка кайту максаты килеп туды. Бу бөек максатка ирешү теләге белән ТР мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин 2014 нче елны Татарстан өммәте өчен Дини гореф-гадәтләрне торгызу елы дип атарга тәкъдим итте. Бу юлда беренче адым булып Болгар шәһәренең Ак мәчетендә татар халкының борынгы ислам гадәтләре буенча бөтен Россия мөселманнарының Мәүлид бәйрәмен үткәрү булды. Икенче адым - Голәмалар шурасының Татарстан мәчетләрендә гыйбадәт кылу гамәлен ортодоксаль ислам кануннарына (фикыһ) туры китерү буенча эше. Бу эшне дин әһелләре бишенче намаз мәсьәләсен караудан башладылар.

АСТРОНОМИЯ СӘГАТЬ ЯРЫМНЫ БЕЛМИ

Бишенче намаз мәсьәләсенә өстенлек бирүнең сәбәбе Россия мөселманнарында ястү намазын кояш баегач сәгать ярымнан соң уку тәртипкә кереп китүгә бәйле. Чөнки элек астрономик исәпләүләрне үткәрү мөмкин булмаган. Монда шуны әйтеп үтәргә кирәк: намаз вакытын билгеләү, мәчетләрнең төгәл Кәгъбәгә юнәлгән булуы кебек гыйбадәт кылу мәсьәләләре үз вакытында бөтен мөселман дөньясында астрономиянең үсүенә китерә. Мөселманнар дөньяга бүгенге көндә дә ачышлары кулланылган атаклы астрономия белгечләрен, гарәп теленнән булган астрономия терминнарын (мәсәлән, зенит, азимут) һәм йолдызлар исемнәрен (Альтаир, Бетельгейзе, Мицар һ.б.) бирәләр.

Бу уңышлар кочагында татар дөньясы да үсә. Кайбер тикшеренүчеләр революциягә кадәр бездә намаз вакытлары күрсәтелгән 20 ләп календарь бастырылуы турында язалар. Билгеле татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри да намаз вакытлары язылган үз календарен чыгара. Һәм бу календарьларның берсендә дә ястү намазының кояш баегач сәгать ярымнан соң укылырга тиешлегенә күрсәтмә юк. Татарстан Республикасының китапханә архивларында да андыйларны табып булмый, чөнки Коръәни-Кәрим һәм Пәйгамбәребез (с.г.в.) сөннәте намазны кояш торышына карап үтәргә куша. Татар халкының дин әһелләре революциягә кадәр исәпләүләрдә һәрвакыт астрономия мәгълүматларына таянганнар.

Беренче тапкыр ястү намазын кояш баегач сәгать ярымнан соң уку тәртибе совет чоры дини календарьларында языла башлый. Шунысын әйтеп үтәргә кирәк: бу совет чоры өчен мәҗбүри генә түгел, ә кирәкле чара була. Ул авыр заманнарда илебез мөселманнары өчен ислам диненең нигезләрен саклап калу мөһим иде. Намаз вакытын билгеләүдәге гадиләштерү моңа ирешергә ярдәм итте. Ләкин бүгенге көндә Россия мөселман өммәтенең дини гамәлне фән белән бәйләп үтәргә бөтен мөмкинлекләре дә бар.

ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ӨЧ КИЛЕШҮЕ

Татарстан Диния нәзарәте пленумының намаз вакытларын билгеләүдә астрономик исәпләүләргә күчү карары элеккечә яшәргә күнеккән мөселманнарда сагаю уятты. Бу көннәрдә Голәмалар шурасы һәм Татарстанда дини кануннарның дөрес үтәлешен контрольдә тотучы Казыйлар шурасы телефоннан мөселманнардан килүче күпсанлы сорауларга җавап бирәләр. Һәм бу көтелгән реакция.

Бишенче намаз мәсьәләсенә киңрәк - Мәрҗани һәм Курсави кебек карарга кирәк. Бу гыйбадәт кылу тәртибенә караган сорауның нигезендә без зуррак нәрсәне - тормышыбыз көзгесен күрә алабыз. Бу күзлектән чыгып караганда, Татарстан мөселманнары башлыклары, беренчедән, мирасыбызда язылган Пәйгамбәребез (с.г.в.) исламы кануннары белән килештеләр. Икенчедән, алар татар халкының революциягә кадәр сакланып килгән гореф-гадәтләре белән килештеләр. Һәм, өченчедән, алар борынгы заманнардагы кебек бүгенге көн фән казанышлары белән килештеләр. Бу өч килешү безнең халкыбызга һәрвакыт хас булган һәм заманында халкыбызны ислам дөньясының алдынгы урынына чыгарган.

Рөстәм БАТЫР,
Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары

МАКСАТ — ҮЗГӘРЕШ КЕРТҮ ТҮГЕЛ, ГЫЙБАДӘТЛӘРЕБЕЗ ДӨРЕС БУЛСЫН

Мәгълүм булганча, февраль аеннан намаз уку вакытларына үзгәрешләр керде. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте республикадагы мөселман календаре чыгаручыларны җыеп, әлеге үзгәрешләрнең сәбәпләрен аңлатты.

Нәзарәтнең Голәмалар шурасы рәисе Габдулла хәзрәт Әдһәмов сүзне ерактанрак - халкыбызның исламны кабул иткәннән соңгы тарихыннан башлады:

- Ибн Фадланның X гасырдан килеп ирешкән язмасы һәммәбезгә мәгълүм. Болгарга ул җәй көне килә, төннең иң кыска чагында. Язмадан күренгәнчә, ул вакытта болгарлар ахшам белән ястүне бергә укыганнар. Урта гасырларда исә болгарларда ястү намазын укымаска дигән фәтва булган. XVIII гасырның ахырында ястү намазы мәсьәләсе яңадан күтәрелә башлый, ниятнең төрле формаларын тәкъдим иткән, каза кылып укырга дигән фәтвалар чыга. Күргәнегезчә, бабаларыбыз шәригатькә туры килә торган җавап эзләгәннәр. XIX гасырның башында атаклы галимебез Габденнасыйр Курсави, ястү һәм иртәнге намазларның бер вакытын билгеләргә кирәк, дигән тәкъдим белән чыга. Мәшһүр галимебез Шиһабетдин Мәрҗани "Назурат әл- хакк" дигән хезмәтендә Курсави тәкъдименә фәнни дәлилләр куша. Шулай итеп, XIX гасыр ахыры - XX гасыр башында намаз вакытларын күрсәткән төрле календарьлар чыга башлый. Без аларны да өйрәндек, бабаларыбыз намаз вакытларын астрономик исәпләүләргә нигезләнеп билгеләгәннәр. Кызганычка, совет заманында бу традиция туктатыла. Инде үзгәртеп кору елларында дин кардәшләребез уйлана башлый. Һәм ясалма рәвештә иртәнге намазны кояш чыккан чы, ястү намазын кояш баеганнан соң сәгать ярым үткәч укырга дип билгеләнә. Әмма бу дөреслеккә бик үк туры килми. Әлеге мәсьәләне Голәмалар шурасы тикшерде һәм узган елның декабрендә астрономик хисапка кайтырга дигән карарга килдек. Тәкъдимебез гыйнвар аенда узган пленумда кабул ителде.

Голәмалар шурасы әгъзасы, башкалабызның Әмәт бистәсе мәчете имам-хатыйбы Равил хәзрәт Бикбаев намаз вакытларының ничек чутланышына тәфсилләбрәк тукталды:

- Аллаһы сөбханә вә Тәгалә намаз гыйбадәтен кояш йөрешенә карап кылырга билгеләде. Кояш зәвәлдән авышса - өйлә вакыты җитә, зәвәл шәүләсеннән тыш ике шәүлә булса - икенде, кояш баеса - ахшам, шәфәкъ кызыллыгы яки аклыгы беткәч ястү җитә. XX гасырга хәтле бездә егермегә якын календарь чыккан, аны төзүчеләр намаз вакытларын астрономик исәпләүләргә нигезләнеп билгеләгәннәр. Алар моны ничек исәпләгәннәр соң? Кояш офыктан 18 градуска төшеп киткәч, шәфәкъның аклыгы, 15 градуста кызыллык бетә. Ә кояш чыга башлаганда офыкта (18 градуста) аклык беленә башлый, 15 градуста кызыллык тарала. Менә бу кояш йөреше. Намаз вакытларын алар менә шулай чутлаганнар. Бөтен Җир шарында мөселманнар намаз вакытларын градуслар белән билгелиләр. Өйрәнә башлагач аңладык - 18 градус аклыкка бәйле икән. Моны мөселман галимнәре инде X гасырда ук белгәннәр. Хәнәфи мәзһәбендәге күпчелек галимнәр, кызыллык беткәч ястү керә, диләр. Без дә ул фикергә таяндык. Әмма бер проблема килеп туды - җәй көнендә 5 май белән 8 август арасында шәфәкъ кызыллыгы һәм аклыгы бетми. Без бик күп галимнәрнең фикерләрен өйрәндек. "Хәшия ибн Габидин" китабында шәфәкъ кызыллыгы бетә торган төбәккә карап билгеләргә диелгән. Әлеге фикерне Галимҗан Баруди "Хөснел-гыйбадәт" китабында дөрес дип саный. Шуңа күрә без ул төбәкнең намаз вакытларына туры китереп, ястү намазын кояш баегач сәгать ярым узгач укырга, ә сәхәр вакытын кояш чыккан чы ике сәгать кала дип билгеләдек. Безнең максат үзгәртергә теләүдән түгел, гыйбадәтебез дөрес булсын иде.

Татарстан мөфтие урынбасары Рөстәм Хәйруллин да календарь төзүчеләргә кайбер теләкләрен җиткерде:

- Аллаһы сөбханә вә Тәгалә һәрберегездән разый булсын. Кайсы районга барсак та, халык сез чыгарган календарьларны укый, рәхмәт әйтә, савабы сезгә кайта. Әмма кайчакта шушы календарьлар аркасында шактый четерекле хәлләр дә килеп чыккалый. Чөнки бер календарь, болай ярый, ди. Икенчесе, болай ярамый, тегеләй кирәк, ди. Аллага шөкер, Голәмалар шурасы, Казыйлар шурасы бар, мөфти хәзрәтебез дә бик галим кеше, шушы календарьларны, китапларны лицензияли торган үзәкне булдырды. Шушы уңайдан җыелышуыбыз файдалы булсын, гореф-гадәтләребез дә, башка тәртипләребез дә бертөрле булсын, авылларда, республикабызда тынычлык булсын иде.

Нәүбәһар КӘБИРОВА

КОРЪӘННӘ ҮЗ ТАВЫШЫГЫЗ БЕЛӘН БИЗӘГЕЗ

КОРЪӘН УКУ ӘДӘБЕ

1. Коръән укучы кешенең тәһарәтле булуы лазем. Киеме дә чиста булу тиешле, шулай ук мисвәк һәм хушбуйлар куллану яхшы. Галидән (р.г.) тапшырыла, Пәйгамбәребез (с.г.в.) болай дигән: "Хакыйкатьтә, сезнең авызларыгыз - Коръән юллары, шуңа күрә аны (авызыгызны) мисвәк белән чистартыгыз".

2. Коръән уку өчен йөзең белән Кәгъбәгә таба юнәлергә кирәк.

3. "Тәхият" торышында утыру мәгъкуль.

4. Көнлек уку күләменә килгәндә исә, әлеге мәсьәлә буенча галимнәр тормышыннан күпләгән мисаллар китерергә мөмкин. Мисал өчен, имам Шәфигый һәм Салих ибне Кыйсан рамазан ае җиткәндә бар Коръәнне көненә икешәр тапкыр укып чыккан. Имам Нәвавиның "Әл-Әзкар" китабында Ибне Кәтибнең Коръәнне көндезләрен һәм төннәрен дүртешәр тапкыр укып чыккан-лыгы әйтелә. Галимнәрнең кайберләре Коръәнне аена бер тапкыр укып чыккан.

Габдуллаһ ибне Әмирдән (р.г.) тапшырыла, Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткән: "Коръәнне шул кеше аңламады ки, кем аны өч көннән дә кимрәк укыды".

Имам Гыйракый бу мәсьәләгә карата болай дип әйткән: "Югарыда китерелгән хәдис күп кенә хәдис җыентыкларына кергән. Аның мәгънәсе шуннан гыйбарәт ки, әгәр кем дә булса бар Коръәнне өч көннән дә кимрәк вакыт аралыгында укып чыкса, ул аны яхшылап аңлый алмаячак, чөнки аның, тиз укуы сәбәпле, Коръәнне аңларга (мәгънәләренә төшенер өчен) вакыты булмаячак. Әмма бу Коръәнне өч көннән дә азрак вакыт эчендә укып бетергән кеше ярамаган эш эшләгән дигәнне аңлатмый, Госман ибне Гаффан, Тамими Дари, Сәед ибне Җүбәйр (Аллаһ алардан разый булса иде) кебек күренекле шәхесләрнең бар Коръәнне намазның бер рәкәгатендә укып бетерүләре турындагы хәбәрләр безгә кадәр килеп ирешкән бит".

"Бөстанел-Гарифин" китабында имам Әгъзамнан түбәндәгеләр китерелә: "Аны елына ике тапкыр укып чыксыннар өчен Коръән хакы бар, чөнки Аллаһ Илчесе (с.г.в.) үзенең вафатына бер ел кала Җәбраил галәйһиссәламгә Коръәнне ике тапкыр укыган".

5. Сыктарга (еларга) тырышу. Коръән тыңлаучы Үзенең дуслары турында Аллаһы Тәгалә Үзе сөйли: "Ахирәткә ышанмаганнарга килсәк, алар өчен әрнетүле газап әзерләнгән" ("Исра (Төнге йөрү, Ягъкуб угыллары)" сүрәсе, 10 нчы аять).

Бер галимнән сораганнар: "Ни өчен без Коръән укыганда сәхабәләр (Аллаһ алардан разый булса иде) елаган кебек еламыйбыз?" Ул болай дип җавап биргән: "Бары тик шуның өчен, сәхабәләр тәмуг әһелләре турында укыганда аларның арасында булырбыз дип курыккан, һәм елаганнар, ә без һәрвакыт анда кемдер, һич тә без түгелдер дип уйлыйбыз. Ә Аллаһ Илчесенең (с.г.в.) сәхабәләре Коръәндә җәннәт әһелләре турында укыганда, алар: "Без аларга никадәр ерак!" - дип әйткән, аннары күз яшьләре түккәннәр, ә без, җәннәт әһелләре турында укып, үзебезне инде алар янында кебек хис итәбез".

6. Әгәр сезнең кеше күрсәнгә уку яки башка кешеләргә кыенлыклар тудыру ихтималлыгыгыз булса, Коръәнне әкрен генә, киресенчә булганда - кычкырып укырга кирәк. Аны ашыкмыйча, тукталышлар ясап уку тиешле, хакыйкатьтә, укуның максаты - укылганның күләмендә түгел, ә Коръән аятьләре белән уйлануда.

Динебезгә зур тырышлык куйган Үммә Сәламнән (Аллаһ аннан разый булса иде) Аллаһ Илчесенең (с.г.в.) Коръәнне ничек укуы турында сорагач, ул (Аллаһ аннан разый булса иде) аның кыска паузалар ясап, бер аятьне икенчесеннән аерып укуы турында әйтә.

Ибне Габбастан тапшыралар, Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткән: "Мин, бар Коръәнне тиз генә укып чыгуга караганда, "Бәкара" һәм "Әли Гыймран" сүрәләрен акрын, уйга бирелеп укуны күбрәк яратам".

7. Матур итеп, көйләп уку. Сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) болай дигән: "Коръәнне үзегезнең аһәңегез (тавышыгыз) белән бизәгез".



АЛЛАҺНЫҢ ИЛЧЕСЕ ВАКЫТЫНДАГЫ ХАФИЗЛАР

Тарихта Аллаһның Илчесе (с.г.в.) яшәгән вакытта ук Коръәни-Кәримне тулысынча ятлаган җиде хафиз билгеле, һәм нәкъ менә аларга барлык кыйраәт имамнарының унысы да таяна:

1. Госман ибн Гаффан (р.г.). Аның шәкерте Мүгыйра ибн Әбу Шиһаб булган.

2. Гали ибн Әбу Талиб (р.г.). Аның ятлау ысулы буенча ике риваять бар. Беренчесе буенча, ул бар Коръәнне Аллаһның Илчесе (с.г.в.) яшәгән вакытта ук ятлаган. Икенче риваять буенча, аның үзенә караганда, Гали (р.г.) Аллаһ Илчесе (с.г.в.) инде алар арасында булмаганда Коръәнне ятлап бетергән. Галинең (р.г.) күренекле укучылары: Әбу Габдүррахмән әс-Сүләми һәм Әбүль-Әсүәд әд-Дүәли.

3. Үбәй ибн Кәгеб (р.г.). Ул (р.г.) - Коръәни-Кәримне укыган өчен Аллаһ Илчесеннән (с.г.в.) мактауга лаек булучыларның берсе. Аннан кыйраәт дәресләрен Ибне Габбас, Әбу Һүрәйрә, Габдулла ибн Саиб, Габдулла ибн Гайаш, Әбу Габдүррахмән әс-Сүләми (Аллаһ алардан разый булса иде) кебек сәхабәләр алган.

4. Габдулла ибн Мәсгуд (р.г.). Ул (р.г.) Коръәнне тулысынча ятлаган, өстәвенә җитмешкә якын сүрәне Аллаһ Илчесенең үзеннән өйрәнгән. Ул Галькама ибн Кайс, Мәсрукь ибн Гажда, Әсүәд ибн Язид, Зир ибн Хүбәйш, Әбу Габдүррахмән әс-Сүләми кебек хафизларның остазы булган.

5. Зәед ибн Сабит (р.г.). Әбу Бәкер (р.г.) аны Коръәнне бер китапка җыю буенча җитәкче итеп билгели. Моннан тыш, ул Госман (р.г.) хәлиф булганда мөсхәфләрне (Коръән экземплярларын) күбәйтүдә һәм таратуда катнашкан.

6. Әбу Муса әль-Әшгари (р.г.). Аллаһ Илчесе аның тавышын Дауд галәйһиссәлам аһәңенә охшаткан. Аның шәкертләре Әбу Раҗә аль-Гутариди һәм Хыйтан ибн Габдулла ар-Ракаши булган.

7. Әбу Дәрдә (Гуәймир ибн Зәед) (р.г.). Ул Димәшкъта казый булган һәм «Кари-и Димәшкъ» исеме белән танылган. Аның шәкертләре арасында Гатыя ибн Кайс, Халид ибн Мәгдан, җирлек казые Бәгләбакка Сүәйд ибн Габдүльгазиз һәм хәтта Үммү Дәрдә исемле бер хатын-кыз да булган.

Аллаһ Илчесенең сәхабәләре саныннан танылган хафизлар Изге Мәккә шәһәрендә һәм Нурлы Мәдинәдә, шулай ук Куфәдә, Басрада, Димәшкъта һәм Мисырда дәрес биргән. Шул рәвешле алар анда үзләреннән соң бу мәртәбәле эшне дәвам итә алырлык Коръәнне яхшы белүчеләрне калдырган. Мисал өчен, Госман (р.г.) Мүгыйра ибн Әбу Шиһаб әль-Мәхзумигә мөгаллимлек иткән, ул исә, үз чиратында, кыйраәт имамнарының берсе булган Ибне Әмирне өйрәтеп калдырган. Җиде кыйраәт имамы үз белемнәрендә Үбәй ибн Кәгеб, Зәед ибн Сабит, Әбү Дәрдә, Габдулла ибн Мәсгуд, Госман һәм Гали (Аллаһ алардан разый булса иде) кебек сәхабәләргә таяна.

ХАҖНЫ КИЧЕКТЕРЕП ТОРЫРГА ЯРЫЙМЫ?

Әлеге сорау буенча галимнәр арасында фикер төрлелеге күзәтелә. Әбу Сәхел әз-Зажаҗи әлеге фикер каршылыкларына мөнәсәбәттә болайрак аңлатма биргән: бу фикер каршылыгы имам Әбу Йосыф һәм имам Мөхәммәд (рәхмәтуллаһи галәйһимә) арасында. Әбу Йосыф (рәхмәтуллаһи галәйһи) фикере буенча, мөмкинлекләр (барлык шартлар) барлыкка килү белән хаҗны быел ук үтәү мәҗбүри (фарыз).

Имам Мөхәммәд (рәхмәтуллаһи галәйһи) исә, үз чиратында, хаҗ кылу мәҗбүри була, әмма нәкъ менә бу елда ук түгел, дигән фикердә торган. Ягъни, адәм баласы хаҗны быел да һәм алдагы елларда да үти ала. Сүз уңаеннан шунысын да әйтәсем килә: әлеге фикер белән имам әш-Шәфигый (рәхмәтуллаһи галәйһи) да килешкән. Имам Әгъзам (рәхмәтуллаһи галәйһи) тарафыннан исәике фикер китерелә, ягъни "шундук фарыз була" һәм "чикләнмәгән вакытка фарыз була".

Мәсьәләне тикшерүгә керешкәнче имам Мөхәммәднең (рәхмәтуллаһи галәйһи) карашын карап үтик.

Аллаһы Тәгалә хаҗны вакыт ягыннан чикләүләр куймыйча мәҗбүри итеп йөкләгән. "Әли Гыймран (Гыймран гаиләсе)" сүрәсендә (97 нче аять) болай диелгән: "Анда ап-ачык аятьләр, Ибраһим баскан җир бар. Анда кергән кеше иминлектә булыр. Юлын тапкан (көче җиткән, хәленнән килгән) (барлык) кешеләрне Аллаһ ризалыгы өчен анда (хаҗга) барырга бурычлы итте. Берәрсе инкяр итә икән, Аллаһ аңа (һәм галәмдәге бернигә дә) мохтаҗ түгел".

Үтәү вакытына килгәндә исә, Коръәндә болай диелгән: "Хаҗ билгеле бер айларда кылына".

Шул рәвешчә, без хаҗны гомереңнең теләсә кайсы елындагы билгеле бер айларда кылырга була икәнлеген аңлыйбыз. Коръән безгә вакыт буенча чикләүләр куймый, шуңа күрә хаҗга бу елны (билгеле бер елны) бару мәҗбүри дигән раслау нигезсез булып санала.

Шулай ук, шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: Мәккә һиҗри исәп буенча 8 нче елда яулап алынган, ә безнең сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) хаҗны бары тик 10 нчы елда гына кылган. Әгәр дә хаҗ кичекмәстән үтәргә тиешле гыйбадәт төре булган булса, Аллаһның илчесе (с.г.в.) аны үтәү вакытын кичектереп тормаган булыр иде.

Ләкин, безнең тарафтан югарыда телгә алынганча, имам Әбу Хәнифәдән (рәхмәтуллаһи галәйһи) әлеге мәсьәлә буенча ике риваять китерелә. Әмма аның ышанычлырагы - хаҗ кичектерелмичә, бу елда ук кылына дигәне. Ә хәзер, әйдәгез, имам Әбу Хәнифә һәм Әбу Йосыф (рәхмәтуллаһи галәйһимә) карашларына күчик. Хаҗ кылу боерыгы билгеле бер вакыт белән конкретлаштырылмаган. Ягъни, аны шул ук елны, яки киләсе елларда үтәү мөмкинлеге бирелгән. Әмма иң яхшысы - аны быел үтәп калу (мөмкинлегең килеп чыгу белән үк). Хаҗ кылуны гел-гел кичектереп килү исә, нинди дә булса сәбәпләр аркасында, әлеге гыйбадәтне үтәүдән колак кагуга китерергә мөмкин.

Шулай итеп, әгәр имам Мөхәммәднең (рәхмәтуллаһи галәйһи) фикерен алсак, мөмкинлеге булып та хаҗ кылуны кичектерүчеләр табылачак, һәм бу кешеләр өчен зыянга булырга мөмкин. Әгәр икенче фикерне - тиз арада (кичекмәстән) кылу фикерен алсак, монысы барыбыз өчен дә иң кулае булыр. Сүз уңаеннан, имам әл-Хүда Әбу Мансур әл-Мәтуриди (рәхмәтуллаһи галәйһи) да мөмкинлегең булу белән үк хаҗ кылу яклы. Аның фикеренчә, теләсә нинди боеруның (мотлакның) билгеләнгән аралыгы юк, алдагы (хәзерге) вакытны күздә тотарга кирәк (ягъни шундук эшләргә).

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН

НӘСЕЛНЕ САКЛАУ – МИЛЛӘТНЕ САКЛАУ УЛ

Ислам дине үсешенә үз өлешен керткән, әмма болгавыр чорларда исемнәре дә онытыла язган мәшһүр галимнәребез бар безнең. Аларның мирасы барланып, әкренләп халыкка кайта башлады. Хөсәен Әмирхан - шундый тәгъليматчыларның берсе.

Хөсәен Әмирхан 1814 (1816) нче елны Казанның Яңа Бистәсендә мулла гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе заманының күренекле дин белгече Әмирхан хәзрәт Бохарада укып кайткан, Иске таш мәчеттә имам һәм мөдәррис булып торган. Хөсәен башлангыч белемне әтисендә ала, аннары Чистай, Бохара мәдрәсәләрендә укый. Әтисенең эшен дәвам итеп, ислам дөньясында шулай ук күренекле шәхес Байморад хәзрәт янәшәсендә Яңа Бистәнең Иске таш мәчетендә имам вазыйфасын башкара, "Әмирхания" мәдрәсәсендә укыта. Ул татар телендә Коръән тәфсире "Әл-Фәваид"ның, мәшһүр "Тәварих-е Болгария"нең (Болгар тарихы) авторы.

Ислам дине тәгъليматчысы Хөсәен Әмирханның тууына 200 ел тулу уңаеннан Казанның Ярдәм мәчетендә "Хөсәен Әмирхан һәм традицион мөселман мәхәлләсе моделе" дигән фәнни-гамәли конференция үткәрелде. Аны Ярдәм мәчете, "Әмирхания" фонды, Россия ислам институты, Татарстан Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты хезмәткәрләре бергәләп оештырды.

Ерак араларны якын итеп конференциягә килгән Чувашия, Мәскәү һәм Үзәк төбәк мөфтие Әлбир хәзрәт Крганов: "Рухи һәм милли хисләребезне, милли кыйммәтләребезне саклауга бигрәк тә игътибарыбызны юнәлтергә тырышу кирәк. Хөсәен Әмирхановлар диннең, милләтебезнең бик кадерле көчләре иде. Һәм алар чын мәгънәсендәге татар зыялылары, берничә йөз еллар буена динебезгә, милләтебезгә хезмәт итәргә тырышкан олуг затлар. Ул - гыйлем иясе, китаплар, мәдрәсәләр булдырып, шул гыйлемен милләтебезгә чәчеп, башкаларга биргән кеше. Ә менә традицияләр, гореф-гадәтләр турында сөйләгәндә, кайберәүләр аны зарарлы әйбер кебек күрсәтергә тырыша. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам дә үзенең чиста нәселдән булуы турында әйткән. "Мин пәйгамбәрләрнең әфәндесе",-дигән. Нәселнең кадерен, исемен саклау - милләтне саклау бит. Шуңа күрә нәселне саклау турында да уйлыйсыбыз бар",- диде Әлбир хәзрәт Крганов.

Әлеге мәҗлестә Хөсәен Әмирханның туганы, "Әмирхания" фонды рәисе, галим Илдус Әмирхан, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының урта гасырларны өйрәнү бүлеге мөдире Илдус Заһидуллин, КФУ доценты, филология фәннәре кандидаты Азат Ахунов һәм башкалар әтрафлы чыгышлар ясады.

Хатыйп ГӘРӘЙ

Иске таш мәчет

Хөсәен ӘМИРХАН тарих белән кызыксынып китүен болай белдерә: "Һәр йорт хакында хәлләрен, галимнәрен һәм вакыйгаларын аңлатып, төрле телләрдә язылган могтбәра тарих китаплары бар. Безнең Болгар йорты, борынгыдан бөек имам йорты булып, бөек галимнәр алдында абруйлы йорт булганы фикыһ китапларыннан билгеле. Күп китапларда "Шәһри Болгар" дип искә алына. Шуңа карамастан, гаҗәп, абруйлы һәм игътибарга лаеклы бер тарих китабы юк..." Гомере буе тарихи чыганакларны өйрәнеп, шактый гыйлем туплаганнан соң, 1883 нче елда ул "Тәварих-е Болгария" (Болгар тарихы) хезмәтен бастыра. Җирле чыганакларны, халык риваятьләрен, галимнәрнең кулъязмаларын файдаланып язылган бу әсәр зур әһәмияткә ия. Татар халкының үткәнен ышанычлы чыганакларга таянып язарга кирәк - автор әнә шундый проблема күтәрә. Шактый вакытлар бу хезмәт мәктәп-мәдрәсәләрдә дәреслек буларак кулланыла. Китапта Болгар, Казан, Кабан күле, Казанның яулап алынуы, Иске Бистә, Яңа Бистә, Черек Күл кыйссалары, мәшһүр шәхесләр тормышы, тарихи вакыйгалар сурәтләнә. Бүгенге сәхифәдә "Тәварих-е Болгария"дән өзекләр тәкъдим итәбез.

ЧЕРЕК КҮЛ КЫЙССАСЫ

Ул урында бер зур агач булып, тирәсе камышлык, баткак су чыгып, кечкенә генә күл күк булып яткан җир икән. Ул заманда булган урыс җәмәгасы: "Безнең халыктан элек заманда бер зур әүлиябез кешеләрдән качып килеп, Гайсәгә җитсәм дип күп ел гыйбадәт кылып, үлгәч Гайсә төшеп шунда дәфен кылган", - дип, һәр якшәмбе көн килеп үзләренчә гыйбадәтләр кыйлып, шул агачны зиярәт әйләп фәкыйрь-фәкарәләргә акчалар өләшеп китәләр икән. Ул агачка җеннәр ияләнгән икән. Болар килгән вакытта алар төрле уеннарга охшашлы кычкырышалар икән. Килгән кешеләр: "Безләрнең догабызны кабул кылды, безгә изгелек белән җавап бирде", - дип бик шатланып китәләр икән. Ничә вакыттан соң бер гайрәтле поп, якшәмбе көн халык җыелып килгәндә киемнәрен ертып, чәчләрен йолкып, йөзен канатып, шул агачка асылып, һич нәрсә белмәмеш булып антлар итеп, "Инҗилен" муенга асып, аһ-вах әйләп егылап җыелган халык арасына үзен ташлап: "Бу әүлия мине кулымнан тотып әүвәл бик орышып, соңра нәсихәт кыйлып әйтте: "Әй Гайсә кауеме. Мин Гайсәнең бик яраткан әүлиясемен. Мине бу урынга үзе күмде һәм: "Бу җирдә бер шәһәр булыр, Гайсә дине бик куәтләнер, шунда бул, алар арасында. Алар аза башласалар, кешеләрнең төшенә кереп кисәтерсең", - дип әйтте. Гайсә әйткәнчә булды, мин сине бу шәһәрдә булган Гайсә кауеменә нәсихәт кыйлырга үз тарафымнан урынбасар әйләп әмер кыйлам. Гайсә динен нык тотып якшәмбе көнендә эш кылмасыннар, атна арасында кылган эшләренә тәүбә кыйлсыннар, попларны бик хөрмәт кыйлсыннар, аларның ачуын китермәсеннәр, бу урынның кадерен белмәсәләр, мин күчәрмен, бу шәһәр хараблыкка төшәр, бу сүзләремне Гайсә кауеменә әйт", - дип минем авызыма төкерде, эчемә нур тулып уяндым", - дип халыкка әйтеп инандырган. Ул попка шул вакытта бик ихлас әйләп күп нәрсәләр биреп, попны алтын вә көмеш астында калдырганнар. Поп: "Чурт знает, морадым булды", - дигән. Халык аңламаган. Шул попны шул урынга караучы итеп, шунда берәве гыйбадәт кыйлырга кечерәк урын салдырып, бик әрчеп төзекләндергәннәр. Ничә заман шул рәвештә булып, халык бик артык эш кыла башлагач, бер әрхәрәй бу эшкә гаҗәпләнеп, ул попның вакыйгасы ялгандыр, безнең книгәләрдә күренми, дип ул юлдан тыеп, харап булмасын, дип гади халыкка тамаша урыны кылганнар. Күп заман үтмәктән, ул агач череп егылып, агачны байлар бүлешеп алып, урынында булган күлне "Черек Күл" дип атаганнар. Бу кыйссалар Залим гаййар берлә Галим казыйның Галим угрының кулына төшкәне турындагы кыйссасына охшыйдыр.

Казан урыс алганда кечкенә генә йорт икән. Болакның югары тарафында, хәтта югары урамнарда да өйләр юк икән. Печән базары урыны сазламык, су баткан җир икән. Кибет урыннары зиярәт булган җир икән. Төп казанлык Казан төзелгәндә килеп калган адәмнәр токымыннандыр. Алар Болгардан күчеп килгәннәр. Әби падишаһ заманынача булган падишаһлар ислам әһленә каршы булган. Ләкин ислам дине шәрафәтендә яхшы галимнәр булган. Шәригать хөкеме мөселман халкында галимнәр тырышлыгында киселмәгән, кечкенә булса да мәсҗед һәм мәдрәсәләр булган. 1777 нче елда Әби падишаһ булып, дин илә булышмасын дип хөкем әйләгән һәм Ислам хакында Хытай ханы булган Чин хаканы хикәятен сөйләп ислам диненә һәм куәт биреп мәсҗедләр салырга әмер әйләгән.

ХИКӘЯТ

Хытай ханына бер көн вәзирлә-ре җыелып диделәр ки, ислам әһлен безнең илә катыштыр, богдай эчендә салам кеби боларны пакь итәрбез вә булыр мал һәм җиребез, хәзинәгә файдалары булыр. Боларга чин хаканы өч төрле дәлил берлә җавап бирде. Бере будыр: "Бабаларыбыз бу эштә тырышлыклар күрсәткәннәр, без ничек итик?" Икенче: "Безнең хөкемебез боларның күз алдындадыр, боларда бер бозык эш күренгәне юк, яшерен эшләреннән ни мәслихәтебез бардыр?" Өченчесе: "Ни булыр ди безгә дәхи аңларның дине насыйб булып, безләр дә алар кеби мөселман булсак иде", - дип. Хаканның моның күк кайбер эш һәм сүзләре вә хәрәкәтләреннән аңлашылыр ки, хакыйкатьтә мөселман булып мәмләкәте китүдән куркып күрсәтмәс, яшереп тотар... (Чин тарихы).

ЯҢА БИСТӘ

Яңа Бистә халкы күчүдән элек Пукруфкада икән. 1773 нче елда Пугачау елы икән. Казанда Каратун Ычтапан углы княз Мещерский наместник булып, бу халык монда тормасын, дип әмер әйләгән. Бу халык арасында Мөхәммәд мирзаның бабасы бар икән. Ул ничә адәмнәр белән барып, Яңа Бистә урынын сорап, әүвәл шулар күчкән. Мәхәммәд мирзаның углы Шаһи Алкин. Асыллары тау ягыннан, урыс Казанны алганда Тау як мирзалары күп хезмәтләр күрсәтеп, мирзалыкны алганнар. Шул сәбәптән, аларның сүзе мәкъбул икән. Шуның өчен Мирзалар башы дигәннәр, хәзер дә шулай мәшһүрдер. Мөхәммәд мирзаның бабалары кауеме илән килеп зур гыймарәтләр вә бакчалар кылганнар. Ул вакытта сиксән ике йорт булып күчкәннәр. Иске Бистәдән күчмәктән моны Яңа Бистә дигәннәр. (Мин әйтәм бу юл илә булдыкта Яңа Бистә димәккә башка сәбәп булмак вә һәм Каргалының Сәгыйд бистәсен шаһит әйләмәк дәлилсез сүз булса кирәк. Һәр нәрсәгә бер сәбәп дәлил булмыйдыр, асылы һәммәсе кыйссa вә хикәядер, бер кагыйдәгә туры килмәс).

Вәли белән Рәшитне никахлаштырмыйк!

Дөньяда глобаль җылыну процессы башланды, диләр. Җир шары җылына, кышлар бетә, диңгез-океаннар үз ярларыннан чыгачак, имеш. Барысы да кайгыра, аны туктатырга тырыша. Төрле дәүләтләр һәм оешмалар шушы җылынуга каршы тору ысулларын эзли. Кемнәрдер диңгездә йөзүче нефтьчеләр белән көрәшә, кемнәрдер заводларның кара төтен чыгарып ятуын туктатмакчы. Боларның эше читтән бик көлке күренә. Ләкин бүген без күреп ияләшкән тирә-юнь, чыннан да, үзгәрә бара. Шәһәр һәм авыл халкы моны күреп тора, телиме-теләмиме кеше күңеле уйлана һәм кайгыра башлый.

Бу глобаль процесслар җәмгыятебезгә дә үтеп керде. Тәрбия төшенчәсе кешеләрнең тормышыннан юкка чыгып бара. Бүгенге яшьләр өчен мәйданга чыгып сугышу, шәһәрләргә зыян салу, урам уртасында хайван кебек зина кылу берни тормый. Яңа гасыр балаларының фикерләре, рухый кыйммәтләре бөтенләй үзгәрде. Барыбыз да бу әхлаксызлыкларны күреп тора: кем газеттан укып, кем телевизордан карап, кем башын тәрәзәсеннән чыгарып моңа шаһит була. Гомумән алганда, Җир шары халкы үзенең җәмгыяви фикерен үзгәртте. Аңа элекке консерватив фикерләр, тыюлы гадәтләр ошамый башлады, аның үзен бернәрсә белән дә чикләмичә яшисе килә. Бу - яңа гасыр, монда яңа кешеләр...

> **Аллаһның ләгънәте булсын шул ир-атка, кайсылары, хатын-кыз сыйфатларын кабатлап, хатыннарга охшаш булырга тырыша һәм шул хатын-кызларга, кайсылары ир-атларга охшаш булырга тырыша. Аларны өйләрегездән, авылларыгыздан куыгыз!**

Әлеге үзгәрешләр арасында төрле мәгънәсезлекләрне күзәтергә була. Аларның кайберләре кешене асыл чикләрдән генә түгел, ә тәмам табигый кысаларыннан чыгарга актив чакыра. Шул яңалыкларның берсе гомосексуализм дип атала. Ягъни, гадирәк итеп әйткәндә, ир-атларның бер-берсе белән гаилә корып, җенси тормышлы булып яшәүләре. Кемгәдер бу эш яңа дөньяның нормасы булып күренәдер, ләкин күпчелеккә, бигрәк тә Россия халкы өчен, бу - гаҗәп һәм кыргый күренеш. Европалылар өчен Россия халкы - руслар, татарлар һәм башкалар модадан артта калган булып саналадыр, бәлки. Бу урында, шөкер, әле дә алар шикелле бик "алга китмәгәнбез", диясе килә...

Ерак булмаган тарихка карасак, әйтик, урта гасырларда бу дәрәҗәдә таралган кабахәтлек күренми. Бәлки андый төркемнәр тарихта булгандыр, әмма әүвәлге гомосексуаллар халыкның һәм дин әһелләренең сүзеннән куркып, аларның ачы җәзаларыннан качып яшәгән. Ислам һәм православиенең гомосексуализмга карашлары бик тә кискен дәрәҗәдә каршы.Ике диннең дә Китапларында шушы мәсьәлә буенча Лут пәйгамбәр кавеме мисал итеп китерелә. Содом шәһәрендә ир-атлар бер-берсе белән зина кылып яшәгән. Аларның җирлегендә бу кабахәт гадәт җәмгыятьтәге гадәти күренеш буларак кабул ителгән була. Ә хатыннарын алар теләмичә, нәселләрен дәвам итү ниятеннән генә тота. Халыкның фикере шулкадәр бозык була ки, хәтта Содом шәһәренең хатыннары, кызлары да моны дөрес, шулай тиеш дип кабул итә. Алар үзләренең ирләренә, улларына каршы чыкмый, гөнаһлы гадәтләрен төзәтми. Кылган кабахәтлекләре өчен соңыннан Содом шәһәре юкка чыгарыла. Ирләр генә түгел, гафил булып, ирләрен тыймаулары сәбәпле хатыннары да, бар нәселләре белән һәлак була. Бу хакта Коръәни-Кәримнең "Хиҗр" сүрәсенең 74-76 нчы аятьләрендә болай диелә: "Шулай итеп, Без алар өлкәсендәге җирнең астын өскә китердек. Башларына яндырылган ташлар яудырдык. Хактыр ки, гыйбрәт алучылар өчен монда хикмәтләр бар. Хактыр ки, алар (хәрабәләр) үтеп-сүтеп йөри торган юл өстендә һаман тора". Башка тәфсирләрдә дә бу хакта аңлатмалар бирелгән.

Ислам дине буенча, гомосексуализм - бик зур гөнаһ. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам әйткән: "Аллаһның ләгънәте булсын шул ир-атка, кайсылары, хатын-кыз сыйфатларын кабатлап, хатыннарга охшаш булырга тырыша һәм шул хатын-кызларга, кайсылары ир-атларга охшаш булырга тырыша. Аларны өйләрегездән, авылларыгыздан куыгыз!".

Бүгенге көндә исә, гомосексуализм Европаның алга киткән илләрендә һәм Америкада тәмам чәчәк атты. Алар шәһәр урталарында гей-кварталлар ясап, ташландык авылларга күченеп, гей-авыллар оештырып ята. Берәүгә дә сер түгел, шушы яңа төркемнәр миллионлаган кешеләрне туплап, вәгазьләп, халыкларның милли һәм дини йолаларын, гореф-гадәтләрен юкка чыгарып маташа. Аек акыллы халык күпме генә каршы чыгып, көрәшеп карамасын, аларның җәмгыятьләре беркайда да эшләүдән туктамады, киресенчә, көннән-көн үсә генә бара. Бу хәрәкәтне хайванлык дип атарга хәтта тел әйләнми, адәм акылына ия булмаган хайваннар да шушы оятсызлыкка бармый.

Читтән килә торган шушы начар гадәтләрне, кызганыч ки, бездә дә эләктереп алырга торучылар бар. Үз-үзләрен тотышлары белән бер җәнесле мөнәсәбәтләргә ишарәләүче егетләрне-кызларны Россия эстрадасы "эшкәртеп" чыгарып кына тора. Тамашачыга үзләрен лестбиянкалар рәвешендә тәкъдим иткән төркемнәрне хәтерлисездер. Шөһрәт казануга, яшьләр арасында зур танылуга ия булырга ашкынучы кызларны, егетләрне җәмгыять фикере дә, хәтта Аллаһның ләгънәте дә туктата алмый. Шуларга карап күпме балалар җенси юнәлешләрен үзгәртә, күпме яшүсмер, мине әти-әнием аңламый дип биек түбәләрдән оча...

Соңгы араларда мондый үзгәрешләр акрынлап татар яшьләренә дә кереп бара, дигән хәвефле сигналлар ишетелгәли. Чөнки һәрбер кешенең йөрәгендә дин белән тулып торырга тиешле урын бар, ә бүген күп йөрәкләрнең бу урынын поп-культура ише чүп баскан. Татар егетләре-кызлары дини һәм милли йолаларын, гореф-гадәтләрен онытып, океанның теге ягындагы ырым-шырымга ышана бара. Безнең халык, яшеннән алып картына кадәр, никтер һәр яңалыкны сулар һава вә шифалы су шикелле "бугазына салырга" әзер. Киносын да, сериалын да, гайбәтен дә һәм кабахәт гадәтен дә, төрле "шайтан туйлары"н да шатланып кабул итә. Бик куркыныч үзгәрешләр чорында яшибез...

Монда, әйе, бу начар, дип сөйләнеп йөрү, дәүләтнең "ачулы йөзен күрсәтеп алуы" гына җитми. Уртак фикергә килеп, кулга-кул тотынышып эшли башларга, традицион гаилә кыйммәтләрен өзми-күймый пропагандаларга, бу эшкә мәгълүмат чараларын да тартырга кирәк безгә.

...Юкса, берзаман Вәли белән Рәшит мәчеткә килеп: "Мулла бабай, безгә никах укыгыз әле", - диярге мөмкин бит, шул заманнардан Аллаһ Үзе сакласын.

Хәбир хәзрәт ХАНОВ,
Чирмешән мәчете
имам-хатыйбы

"УРАМ ДӘГЪВӘТЧЕЛӘРЕ"НЕҢ СОЧИДАГЫ "ДӘГЪВӘТЕ"

Американың Street preachers ("Урам дәгъвәтчеләре") оешмасы активистлары Сочида гомосексуализмны пропагандалауга каршы пикет оештырды. XXII кышкы олимпия уеннары барган шәһәрнең үзәк вокзалы янына алар рус һәм инглиз телләрендә "Аллаһ! Путинга хәерхаһлы бул! Ул гомосексуализм гөнаһына каршы чыкты" дип язылган плакатлар күтәреп килде. Әлеге плакатларда Библиядән өзекләр дә китерелгән иде.

Христианнарда гына түгел, башка монотеистик диннәр буенча да гомосексуализм зур гөнаһлардан санала һәм моның өчен хәтта үлем җәзасы каралган. Изге Коръәндә болай диелә: "Лутны хәтерләгез, ул кавеменә әйтте: "Әллә сез бик яман фәхеш эшне кыласызмы, җитмәсә яшермичә бер-берегезгә күрсәтеп эшлисез. Әллә сез хатыннарны куеп, күп ирләргә якынлык кыласыз, бәлки сез эшегезнең ахыры ничек булачагын уйламый торган җаһил кавемсез"("Нәмел" сүрәсе, 54-55 нче аятьләр). Шулай ук: "Вә Лутның кавеменә әйткән сүзләрен укыгыз: "Тәхкыйк сез бик кабахәт эш кыласыз, ягъни ирләрнең артына барасыз, ул фәхеш эшне сездән алда дөньяда һичбер зат кылмады" ("Үрмәкүч" сүрәсе, 28 нче аять).

Ислам кануннары буенча гомосексуализм һәм зина өчен (дүрт шаһит булган очракта) үлем җәзасы тиешле. Кайбер мөселман илләрендә, аерым алганда, Согуд Гарәбстанында һәм Иранда бу шәригать кануны бүген дә гамәлдә. СССР заманында безнең илдә дә (1993 нче елга кадәр) гомосексуализм өчен законда статья каралган иде. 2013 нче елның июнендә Россия Федерациясе Дәүләт Думасы бер җәнесле мөнәсәбәтләрне пропагандалауны тыючы закон кабул итте. Законны бозучыларга штраф яный.

Бу инициатива Евросоюз илләрендә һәм Америка Кушма Штатларында кискен тәнкыйтькә дучар булды, алар моны дискриминацияләүче закон дип саныйлар. Әмма закон Россия халкында киң яклау тапты. Күрүебезчә, Россия халкында гына да түгел икән...

МӘЧЕТТӘ ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТОТУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

Фәкыйһ Әбу Ләес Әс-Сәмәрканди (Аллаһы Тәгалә аннан разый булсын) үзенең "Тәнбиһел-Гафилин" китабында мәчеткә карата унбиш төрле хөрмәткә лаек гамәл бар дип искәртә:

1) мәчеткә кергәч, анда утырып торган, дәрес алмаган яки зикер әйтү белән шөгыльләнмәгән кешеләргә сәлам бирергә кирәк. Әгәр мәчеттә беркем дә булмаса яки анда булган кешеләр намаз укыса, "Әс-сәламү галәйнә мир-Раббинә үә галә гыйбадиллләхис-Салихин" (Тәрҗемәсе: "Раббыбыз исеменнән һәммәбезгә һәм Аллаһның бар тәкъва колларына иминлек булсын") дип әйтелә;

2) кереп утырганчы ике рәкәгать "Тәхиятел-Мәсҗид" намазы (мәчетне сәламләү намазы) укырга кирәк;

3) мәчеттә сату-алу белән шөгыльләнмәскә, тиҗарәт (сәүдә) эшләре алып бармаска;

4) әгәр үзең белән корал булса, аны чыгармаска;

5) югалткан әйберне эзләмәскә;

6) Аллаһка зикер әйтүдән тыш, тавышыңны күтәреп сөйләшмәскә;

7) мәчеттә дөнья хәлләрен сөйләмәскә;

8) утырган кешеләр өстеннән атлап чыкмаска;

9) урын өчен бәхәсләшмәскә;

10) намаз укыганда үзең белән бер рәттә торганнарны кысрыкламаска;

11) намаз укучылар алдыннан үтеп йөрмәскә;

12) төкерегеңне чәчмәскә;

13) бармак шартлатып яисә шакылдап утырмаска;

14) кечкенә балалар һәм акылга зәгыйфь кешеләр намаз уку урыннарына йомышларын үтәп куйса, аны чистартырга;

15) Аллаһы Тәгаләгә күбрәк зикер әйтергә.

"Әл-Гарәиб" китабында да шундый ук мәгълүматлар китерелә.

Татарстан мөфтие
Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН

МӘЧЕТКӘ... БЕЛЕМ ИЛЕНӘ

Әл-Мәржани мәчете каршындагы "Балалар" үзәгендә белем бәйрәме узды. Үзәккә йөрүче балалар үзләренең дин, әдәп-әхлак, фән өлкәсендә алган белем һәм тәрбия күнекмәләре белән таныштырдылар. Нарасыйларны белем иленә сәяхәттә әкияти геройлар озатып йөрде. Шук маймыл балаларга нинди телдә сорау бирсә, алар аңа җавапны да шул телдә кайтардылар. Чөнки үзәктә балаларга татар, рус, гарәп, инглиз телләре төрле мавыктыргыч уеннар аша өйрәтелә.

Ә иң мөһиме - биредә балалар чын мөселман рухында, әдәп-әхлак кагыйдәләре нигезендә тәрбияләнә. Чарага килгән кунаклар да әнә шуңа игътибар итте. Казан шәһәре имам-мөхтәсибе Мансур хәзрәт Җәләлетдин билгеләп узганча, без җәмгыятькә акыллы, тәрбияле, итагатьле, рәхим-шәфкатьле, белемле балалар тәрбияләргә тиеш. "Дини һәм дөньяви белем һәм тәрбияне шулай бергә алып барганда гына без максатыбызга ирешәчәкбез. Иншә Аллаһ, безнең үрнәктә башка мәчет-мәхәлләләр каршында да шундый үзәкләр ачылыр һәм аларга йөрүче балаларга заманча алымнар белән белем һәм тәрбия биргәндә, ул нарасыйлар инде үскәч, беркайчан да начар юлга басмаслар", - дигән ышанычын белдерә имам-хатыйп.

Үзәккә йөрүче Мәржани оныкларына бүгенге белем бәйрәмендә шулай ук Казан дәүләт химия-технология университеты студентлары дөньяви фән мәҗараларыннан торган шоупрограмма да күрсәттеләр. Соңыннан балалар, әти-әниләре белән берлектә, кул эшләре күнекмәләреннән кораб һәм утрау макетын эшләделәр, тәм-томнар әзерләү буенча мастер-класс үттеләр.

"Балалар" үзәге җитәкчесе Алсу ханым Хафизова сүзләренә караганда, биредә барлыгы 20 бала шөгыльләнә икән. Балалар өчен мондый бәйрәмнең алдагысы, татар халкының гореф-гадәтләре, йолаларына нигезләнгән программаны эченә алачак.

ТАТАР-ИНФОРМ

"Дин тоту иреге кайтты, авыл саен мәчет салдык, ә яшьләр мәчеткә йөрми", - дигән сүзләрне муллалар авызыннан ишеткәч аптырап китәм мин. Йөрмиләр, дип мәчеткә килмәгән кешене сүгеп утырудан мәгънә юк бит инде, җәмәгать. Димәк, алар килерлек итеп эшләргә кирәк.

МУЛЛА БУЛСАҢ, ШУНДЫЙ БУЛ СИН...

Бу турыда бер мәзәк искә төште әле. Дин күтәрелеп кенә килә торган елларда була бу хәл. Авылга эшкә кайткан яшь мулла мәчеткә намазга килгән яшьләрне пыр туздырып тәнкыйтьли икән. "Пычрак киемнән, аякларыгызны да юмыйча мәчеткә килгәнсез. Мәчет әдәбен бөтенләй белмисез икән сез". Авыл егетләре бит инде, кайберсе басудан, җир сукалаган җиреннән килгәндер. Шул чакта ташның үз бакчасына атылуын чамалаган карт мулла болай ди: "Ихлас тырыштым, егетләрне мәчеткә китердем... Инде синең бурычың - аларны тәһарәт алырга өйрәтү". Әзергә бәзер булып кына утырырга ярамый, диюем. Яшьләр, балалар белән эшләмәсәк, ул мәчетләребез буш торачак, билгеле.

Менә безнең Каенсарда бу яктан эшләр, Аллага шөкер, җайланган. Теге дәһрилек чоры дип аталган елларда да Гает намазлары да, җомга намазлары да укыла иде. Чөнки һәрчак ихлас муллаларыбыз булды. Минем мәрхүм бабам Мөхәммәтшакир Оренбургта укып кайткан указлы мулла булган. Аннан соң Шәрәфетдин бабай Галәвиев халыкка диннән бизәргә ирек бирмәде, аның эшен Мөхәммәтзариф абый Хафизов дәвам итте. Хәзерге муллабыз Вәгыйзь абый Хәкимовны авылыбызның гапгади бер трактористы, шаян-шат күңелле кеше дип кенә белә идек. Район үзәгенә барып гыйлем эстәп йөрүен ишетеп хәйран калдык. Яшьләргә дә сүзе үтә Вәгыйзь абыйның, балаларны аеруча үз итә. Ахырзаман белән куркытып, алай итмәгез, болай итмәгез, дип өндәми ул дингә, ә тәмле сүзе белән җәлеп итә. Олы башын кече итеп, мәктәпкә укырга кергән баланы өенә барып котлый, изге теләкләрен әйтә, бүләккә кәләпүшен, дога китапларын да кыстырып килә. Юлында очрасалар, кул биреп исәнләшеп, хәлләрен сораша. Менә шуннан соң сабыйлар да шат, ә ата-ананың күңеле эреп үк китә инде. Минем улларым өчен хәзер авыл мулласы иң гыйлемле, иң абруйлы кеше - менә ничек бит ул уртак тел таба белгәч...

Хәмит БАДИКОВ,
Әтнә районы

Соңгы елларда Татарстанда дини вазгыять тотрыклы түгел. Имамнар арасында төрле юнәлешләр бар, төрле фикерләр яши. Тик без, дин әһелләре, иман мәсьәләләрендә бер юнәлештә эшләргә бурычлы.

ӘБИ-БАБАЙЛАР ЮЛЫ ЫШАНЫЧЛЫ

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин әлеге җаваплы постка билгеләнү белән, без иман һәм гыйбадәт мәсьәләләрендә бер юнәлештә эшләргә, бер фикердә булырга тиеш, дип белдерде. Имамнар алдында ясаган чыгышында ул: "Моннан ике ел элек Татарстан Диния нәзарәте пленумында уртак дини кыйблабыз итеп Әбу Хәнифә мәзһәбен сайлаган идек. Алга таба да эшебезне шушы юнәлеш буенча дәвам итәрбез, иншә Аллаһ. Әлеге мәзһәбтә без теләсә нинди дини соравыбызга җавап таба алабыз, анда һәр дини фикергә дәлилләр бар. Безнең кыйблабыз, илебез, динебез бер. Шуңа күрә башка юлдан китәргә дә, таркалырга да бернинди сәбәп юк. Киресенчә, безгә тагын да берләшергә, бер-беребезгә ярдәм итеп, аңлашып эшләргә кирәк", - дигән максатны куйды.

Без, Әгерҗенең "Хәсән" мәхәлләсе мөселманнары, моңа кадәр дә эшебезне Әбу Хәнифә мәзһәбе буенча алып бардык. Мәчетебездә дини укулар Татарстан Диния нәзарәте тарафыннан расланган программа буенча бара. Быел да мәчетебездә 40 тан артык хатын-кызга, 20дән артык ир-атка дин сабаклары укытабыз. Хатын-кызлар өчен аерым программа бар, ир-атлар өчен - аерым. Дин дәресләрендә мәетне җирләү, соңгы юлга озату, мәрхүмнәрнең җидесен, кырыгын, елын уздыруга кагылышлы тәртипләрне, никах үткәрү тәртипләрен дә өйрәтәбез. Шул рәвешчә үзебезгә алмаш әзерлибез. Шәкертләребезгә күрше хакы, туган якка мәхәббәт, ата-ана хакы, наркомания һәм башка шундый актуаль темаларга тәрбияви вәгазьләр дә сөйлибез.

Корбан, ураза гаетләрен олуг бәйрәм итеп уздыру да матур традициягә әверелде. Узган ел мәчетебез мөселманнары тарафыннан азык-төлек тутырылган 500 пакет әзерләнеп мохтаҗларга таратылды. Корбан гаете көннәрендә мохтаҗларны корбан ите таратып сөендердек. Мөселман кардәшебез Алекс Дәүләтшин һәр елны 1 сентябрьдә мохтаҗ гаиләдә тәрбияләнүче бер баланы мәктәпкә әзерләргә ярдәм итә. Яшьләребез яз-җәй-көз көннәрендә татар зиратында уздырылучы өмәләрдән дә читтә калмыйлар. Ә кышын мәчет тирәсен кардан чистартып, анда һәрчак тәртип булуны күзәтәләр.

Православие руханилары белән бергәләп төрле чараларда катнашу да матур традициягә әйләнде. Шундыйлардан "Террорчылыкка – юк" акциясе, "Җәмгыятьнең йөгәнсезлеге" темасына өлкән сыйныф укучылары арасында узган укулар бүгенге көн өчен аеруча актуаль булып тора.

Киләчәктә дә эшебезне шушы юнәлештә дәвам итәрбез, иншә Аллаһ. Бу юнәлештә эшләү безне тагын да берләштерә, тагын да күркәмрәк гамәлләргә әйди.

Һәр кеше җиргә файда китерү өчен туа. Инде файда китерергә мөмкинлеге булмаса, һәрьяклап башкаларга үрнәк булып торырга тиеш. Без мәчетебезгә йөрүче яшьләргә дә, башка кардәшләребезгә дә һәрчак шушы хакыйкатьне аңлатабыз һәм үзебез дә яшәешебезне шул хакыйкать нигезендә корырга омтылабыз.

Хәлим хәзрәт ЯКУПОВ,
"Хәсән" мәчете
имам-хатыйбы,
Әгерҗе шәһәре.

Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН:

"СЕЗНЕҢ ҖИРЛӘРДӘ КОРЪӘН ИҢГӘН, Ә БЕЗНЕҢ ҖИРДӘ БАСЫЛГАН"

Татарстан мөфтие Согуд Гарәбстанына булган

- Бу - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте делегациясенең Согуд Гарәбстаны Корольлегенең Мәскәүдәге илчелеге чакыруы буенча Эр-Рияд, Мәккә, Мәдинә һәм Җиддәгә кылган рәсми сәфәре иде.

Без дини юнәлеш өчен җавап бирүче күп кенә министрлык җитәкчеләре белән эшлекле очрашулар үткәрдек, шулай ук Согуд Гарәбстанының баш мөфтие, шәйх Габделгазиз ибне Габдулла ибне Мөхәммәд ибне Габделлатыйф әл-Әш-Шәйх белән дә очраштык. Шәйх Габделгазиз республикабыздагы ислам үсеше турында хәбәрдар. Әйтергә кирәк, күзләре күрмәү аңа гыйлем эстәргә комачаулык тудырмаган. Бүгенге көндә ул, шуның өстенә, Голәмаларның Югары Советын һәм Согуд Гарәбстаны Корольлеге Фәнни-тикшеренү һәм фәтвалар чыгаруның сайлап куелган даими комитетын җитәкли.

Сөйләшү барышында Гарәбстан мөфтие Татарстан мөселман-нарын "Хизбүт-тәхрир" һәм "Тәкфир вәл-һиҗра" кебек секталарга иярүдән сакланырга чакырды.

- Согуд Гарәбстаны Корольлеге эшлеклеләре тарафыннан Татарстан ничек кабул ителә?

- Очрашуларның берсендә без Согуд Гарәбстаны Корольлеге Дин эшләре министрлыгының тышкы элемтәләр директоры Габдел Мәҗит Әл-Гомәри белән таныштык. Ул Татарстан турында, татар халкы тәрбияләп үстергән галимнәр турында белә. Мин "Казан басмасы"ның ислам дөньясында мөселманнарның үзләре тарафыннан әзерләнгән беренче басма булуын җиткердем. "Сезнең җирләрдә Коръән иңгән, ә безнең җирдә басылган", - дидем. Үзләренең тарихый мәгълүматларында гарәпләр Казанны Хиҗаз, Истанбул һәм Каһирә кебек калалар вә салалар белән беррәттән телгә ала. Бу бабаларыбызның мөселман дөньясында зур урын тотуын ачык күрсәтә. Татар мөселманнары арасында гарәп телендә бер әйтем бар - "Татар хәйрү бәшәр" (гарәпчәдән - "Татарлар - иң яхшы кешеләр"). Хәзер аның турында гарәпләр дә белә.

Сәфәр вакытында безгә Япония мөселманнары лидеры, доктор Салих Мәһди әс-Сәмараи белән дә очрашу насыйп булды. Без аның белән хәзерге чор мөселман өммәтенең үсеш юнәлешләре турында фикер алыштык.

Бар дөньяга билгеле хәдисләр белгече, хафиз һәм гыйлем иясе Габдеррахман бине Мөхәммәд Ашик белән дә очрашу үткәрелде. Ул - "Тәсхилел Дарури ли Мәсаилил Кодур" китабы авторының улы. Без бу китапны башлангыч мәдрәсәләр программасына керткән идек, оригинал тексты www.darul-kutub.com сайтына куелачак.

- Согуд Гарәбстаны Корольлегендә вакытта нинди дини үзәкләрдә булдыгыз?

- Безнең группабыз Мәккәгә кече хаҗ (гомрә) кылды. Шунда хаҗ эшләре буенча министр урынбасары, министрлыкның Мәккә бүлеге җитәкчесе, доктор Әмир бине Йәсин Фәттани белән очрашу узды. Министр урынбасары Мәккәдә хаҗилар өчен уңайлыклар тудырылуы, әл-Хәрәм мәчетенең зурайтылуы һәм бар дөньядан хаҗиларны кабул итү өчен ниләр эшләнүе турында сөйләде. Мин, үз чиратымда, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан изге җиргә хаҗиларның ни рәвешле әзерләнүе, аерым алганда "ДУМ РТ Хадж" программасын ничек тормышка ашыру турында җиткердем. Сөйләшү барышында Татарстан хаҗиларына хезмәт күрсәтүне яхшырту мәсьәләләрен карадык.

> **"Гарәпләр Казанны Хиҗаз, Истанбул һәм Каһирә кебек калалар вә салалар белән беррәттән телгә ала. Бу бабаларыбызның мөселман дөньясында зур урын тотуын ачык күрсәтә.**

Шулай ук без Изге Кәгъбә өчен япма эшли торган "Кисвә" фабрикасына бардык. Миңа хәтта япманы тегүдә шәхсән катнашып карау мөмкинлеген дә тудырдылар. Коръәни-Кәрим бастыру буенча король Фәһед исемендәге комплексты да булдык. Шунда ук комплекс җитәкчесе белән Коръәннең татар теленә тәрҗемәсен бастыру буенча фикер алыштык. Моннан тыш, без исламның ике мөкатдәс урынына - Әл-Хәрәм мәчетенә һәм Мәдинәдә-ге Пәйгамбәр (с.г.в.) мәчетенә мөнәсәбәте булган "Ике Изге" музеен карадык. Безне музей директоры Мөхәммәд бине Мөслих әл-Җибри үзе каршы алды, аның белән музейның күчмә күргәзмәсен Казанда үткәрү мөмкинлеге турында сөйләштек.

- Сез шулай ук Согуд Гарәбстаны Корольлегенең хаҗ министры Бандар Хаҗар белән дә күрешкәнсез.

- Бу - төрле ил хаҗ вәкилләкләре тарихында Россия делегациясенең тәүге дип әйтерлек рәсми очрашуы. Очрашуда 2014 нче елда Россия мөселманнары өчен хаҗга квоталарны бүлеп бирү мәсьәләсе каралды. Без Әл-Хәрәм мәчетендә бара торган ремонтка бәйле рәвештә Россия хаҗилары өчен квоталарның санын Киметмәү мөмкинлеге турында фикер алыштык.

Бу - вакыйгаларга һәм яңа очрашуларга, файдалы элемтәләргә һәм күркәм башлангычларга бик бай сәфәр булды. Кабул итүчеләргә мин Коръәннең "Казан басмасы"н бик горурланып бүләк иттем. Согуд Гарәбстаны Корольлеге вәкилләрендә безнең илебез һәм аның мөселманнары турында бары яхшы истәлекләр генә калгандыр дип уйлыйм.

Islam-Today

Ришат ХӘМИДУЛЛИН, "ХУЗУР " нәшрият йорты директоры:

"КҮП ӘШЛӘР КАЗАННАН БАШЛАНА"

"Хузур" нәшрият йорты оешуга әле ярты гына ел, ниндидер нәтиҗәләр ясарга, бәлки, иртәрәктер дә. Шулай да, безне беләләр, кызыксыналар икән, аларны бүгенге эшчәнлегебез, алда торган планнарыбыз белән таныштыру урынлы булыр дип уйлыйм.

Нәшрият йорты ачу Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин идеясе иде. Мөселман җәмәгатьчелегендә сыйфатлы дини әдәбиятка, укукыту әсбапларына ихтыяҗ арта баруны исәпкә алып, 2013 нче елның июлендә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан "Хузур" (гарәпчәдән "тынычлык" дигәнне аңлата) нәшрият йорты оешты. Эшчәнлегебезне интернет-сайтлар ясау, китаплар, гарәп, төрек, иске татар телләреннән тәрҗемә ителгән хезмәтләрне бастыру, газета-журналлар чыгару, интернет-радио-телевидение ачу кебек берничә юнәлештә алып барырга ниятләдек.

www.islam-today.ru ислам турындагы мәгълүмати-аналитик, федераль порталы "Хузур" ачылудан бераз иртәрәк - узган елның апреледә үк эшли башлаган иде. Бүгенге көнгә сайтка тәүлегенә уртача 35 мең кеше керә.

Мөселман өммәтенең иң актив өлеше булган мөслимәләребез исә үзләрен борчыган барлык сорауларга җавапларны www.annisa-today.ru сайтында таба ала.

www.baytalhikma.ru интернет-мәдрәсәсе сайтында башлангыч белемнән алып Россия ислам институты базасындагы югары белемгә кадәр төрле әзерлек дәрәҗәләре тәкъдим итәбез. Сер түгел, гыйлем җитенкерәмәү мөселман өммәте өчен бүген дә зур проблема булып кала бирә, шуның аркасында Россия өчен традицион булмаган дини агымнар тарала. Онлайн-мәдрәсә менә бу проблеманы чишүдә ярдәм итәчәк, дип уйлыйбыз.

www.darul-kutub.com электрон китапханәсендә без дин тәгълиматчыларының иң әһәмиятле хезмәтләренең тулы текстлары белән таныштырып барабыз. Эшләгән кешегә эш җитәрлек. Бүгенге көндә Татарстан Республикасы Милли китапханәсе һәм КФУның Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе фондларында 20 меңнән артык кулъязма бар. Әле менә яңа гына Тажетдин Ялчыголның мәшһүр "Рисаләи Газизә" әсәрен хәзерге татар теленә тәрҗемә итеп бетердек.

Яшьләр мохитендә мәгълүмати бушлыкны бетерүне күздә тотып булдырылган www.young-muslims.ru мөсел-ман яшьләре сайты да бүгенге көндә шактый популярлашып килә.

www.namaz-time.com сайтында Россиянең төп шәһәрләре өчен намаз вакытлары, кыйбла тарафы, дога укуның шартлары күрсәтелгән. Соңгы вакытларда намаз вакытлары буенча фетнәләр чыга башлаган иде, шуны истә тотып, без намаз вакытларын КФУ астрономнары белән бергәләп төзедек, Голәмалар шурасыннан раслаттык.

www.halalgid.ru интернет-мәйданчыгында теләсә кайсы кулланучы Россиянең эре шәһәрләрендәге мәчетләрнең, мөселман кафелары, рестораннар, кибетләр, мөселман оешмаларының урнашкан урыннарын белә ала. Уңайлылык өчен аларның интерактив картасы да эшләнде.

Узган көздә без "Татмедиа" матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы белән берлектә татар һәм рус телләрендә "Азан" (radioazan.ru) интернет-Радиосы ачтык. Ул «islam-today.ru» сайтында эшли, тәүлегенә 24 сәгать буе эфирда Коръән аятьләре, күренекле татар имамнарының вәгазьләре, нәшидләр яңгырап тора. Хәзер «Азан» радиосын телефоннарда да тыңларга мөмкин.

Ярты ел эчендә "Хузур" нәшрият йорты 20 гә якын басма китап чыгарды (www.huzur.ru сайтында нәшрият йортының интернет-проектлары белән берәттән барлык полиграфия продукциясе тәкъдим ителгән). Алар арасында гади халык өчен популяр әдәбият та, фәнни хезмәтләр дә бар. Ш.Мәрҗанинең "Назурат әл-хакк" дигән әсәрен гарәп телендә бастырдык. Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның: "Мирасыбыз бай, шуны халыкка кире кайтарсак, гарәпләр үзләре гыйлем алырга безгә килер", - дигән сүзләрендә хаклык бар. Бу китапны күреп саф гарәп галимнәре дә шаккатты. Менә хәзер татар һәм рус телләрендә Әбу Хәнифә турында аудиокитап әзерләдек, аны имамнарыбызга бушлай таратачакбыз.

"Хузур нәшрият йортын тәкъдим итү тантанасы

Нәшрият йортының алдагы планнарына мәдрәсәләр өчен дәреслекләр бастыру да керә. Алар XX гасыр башында кулланылган китапларга нигезләнеп әзерләнәчәк. Милли-дини мирасыбызны халыкка кайтаруны, фәнни хезмәтләр бастыруны дәвам итәргә ниятлибез. Сер түгел, халкыбызның күпчелеге этник мөселманнар. Аларны, гадәттә, гади нәрсәләр борчый. Шуңа күрә популяр әдәбият бастыруны да дәвам итәчәкбез.

Тагын бер күркәм яңалыгыбыз бар: быелдан "Дин вә мәгыйшәт" һәм "Умма" газеталарын яңа форматта, 16 битле, төсле итеп чыгара башладык. Аларның беренче саннары инде укучыларга барып ирешә. Киләчәктә газеталарда күбрәк аналитикага игътибар итәрбез дип уйлыйм.

Вәгазьләр, фәтвалар, актуаль сорауларга җаваплар, әдәби әсәрләрне туплаган "Шура" журналының даны инде бөтен Россиягә таралды, дисәк тә арттыру булмас. Хәзер аның 4 нче саны әзерләнеп ята. Хәзрәтләребезгә ул бушлай таратыла, сатуда юк.

Бүгенге җәмгыять, шул исәптән мөселманнар да, массакүләм мәгълүмат чараларындагы төрле тискәре мәгълүмат йогынтысында яши. Без, мөселман буларак, белемгә омтылып кына моңа каршы тора алабыз. Әгәр дә ислам гыйлеме белән тутырмасак, безнең башларны башкалар үз мәгълүматлары белән тутырачак. Башка белемнәр, башка мәдәният, үзара мөнәсәбәтләрнең башка моделе, башкача яшәү рәвеше белән... Без бүген исламның тышкы образын гына көчләп тагучы телевидение, газета-журналлар, китаплар, уку йортлары һәм, нихаять, сәяси һәм икътисади система ярдәмендә бернинди тирән хисләрсез, исламны сүзе һәм исеме өчен генә кабул иткән мөселманнардан торган җәмгыять төзелү куркынычын тоеп яшибез. Мондый вазгыять ислам турында һәр мөселман белергә тиешле иң аз белемнәргә булса да ия булуны, шулай ук мәдәниятебезне өйрәнүне, гаилә әгъзаларын да шуңа өйрәтүне таләп итә. Бу безгә эчәр суыбыз, ашар ризыгыбыз, сулар һавабыз кебек кирәк. Моннан тыш ихлас гамәлләр кылсак иде. Дин бит ул өч нәрсәдән: гыйлем, гамәл һәм ихласлылыктан тора.

Татарстан мөфтияте йөз ел элек тә, хәзер дә күп кенә файдалы эшләрнең башлангычында торган, күп эшләр Казаннан башланган. Беренче Коръән дә Казанда басылган бит. Хәрәкәттә - бәрәкәт, ди халык, безгә хәзер гел алга барырга кирәк. Бүгенге көндә интернет-телевидение ачу буенча эш алып барабыз, үзебездә видеостудия ясадык, аппаратура алдык. Эшләгән эшебезне күреп, мөселманнар да кузгала башлады хәзер, финанс ярдәме күрсәтергә теләк белдерүчеләр дә бар. Кешене исламга китерүгә сәбәпче булсак, балаларыбызны, оныкларыбызны исламда тәрбияли алсак, без инде Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән максатыбызга ирештек дип санар идек.

XIX гасырның ахыры - XX гасырның башы - татар мәгърифәтчелегенең үсеш чоры. Җәдиди мәктәпләр ачыла, хатын-кызларга да гыйлем алу мөмкинлеге туа. Татар мәгърифәтчеләре арасында Мөхлиса Бубый үзенең гаҗәеп авыр һәм якты тормышы белән аерылып тора. Ислам дөньясында ул бердәнбер татар хатыны-казый була. Халыкта аны "мулла-абыстай" дип йөртәләр. Ул ислам теологиясен һәм шәригать законнарын бик яхшы белә. Халыкның аң-белем дәрәҗәсен күтәрүгә, тәрбияләүгә, мәдәниятне үстерүгә үзеннән зур өлеш кертә. Мөхлиса Бубыйның тормыш юлы бик катлаулы, бары тик көчле рухлы булуы аркасында ул сынмый-сыгылмый.

"Бүгенге көндә татар мөсел-ман хатын-кызлары арасында Мөхлиса Бубый варислары, шәкертләре бармы?" - дигән сорауны күйдым да күз алдыма Әлмира апа ӘДИАТУЛЛИНА килеп басты. Мин аны кечкенәдән телевизор экраннары аша күреп белә идем. Журналистика белән шөгыльләнә башлагач, якыннанрак таныштым.

КҮПЛӘРДӘН БЕРӘВЕ

Әлмира апа 1938 елның 8 июлендә Башкортстан Республикасының Илеш районы Сәеткул авылында Саръяз елгасы буенда туган. Тәхәллүсе дә шуннан алынган икән: Әлмира Саръяз. Аның балачагы Бөек Ватан сугышы вакытына туры килә. Без - яшьләр өчен кызыклы шәхесләр белән аралашу, аларның тормыш сәхифәләренә күз салу - матур бер тарихи фильм карауга тиң.

– Без кушкан эшне җиренә җиткереп, булсын дип эшләргә өйрәнгән буын. Әти-әниләр дә эшкә намус белән карарга өйрәтте. Хәзер бит бер төрле әйтәләр, икенче төрле эшлиләр. Ауамакайлыкка, түбәнлеккә киттe... Шуңа күрә мин җаным-тәнемне биреп, милләтем, телем, динем, Татарстаным өчен өлге һәм үрнәк булсак иде, дип йөрим. Бу балачактан кереп калган, вөҗдан бу.

Сигезенче сыйныфка баргач, мин стена газетасы чыгара башладым. Шатлана-шатлана яза идем инде. Әнә шулай итеп, беренче иҗат адымнарымны Башкортстанның Дүртөйле районы Исмаил авылы урта мәктәбендә ясадым. Аннан соң район газетасыннан кызыксына башладылар, тик ул чакта язып китә алмадым, чөнки укыйсы бар бит әле сигез, тугыз, унны. Комсомолга кердем. Тәртибем, укуым башкаларга үрнәк булсын дигән нәрсә бар иде ул заманда. Без бит совет әдәбиятын укып үстек. Әмирхан Еники, Гариф Ахунов-ның повестьлары чыкты. Шуларны укып, минем Казанга барасы килә башлады. Күңелне филология факультетына укырга керергә дигән уй биләп алды. 1957 нче елны Казанга килдем. Беренче, икенче елны да университетка алмадылар әле. Эшкә урнашырга булдым, әмма күзләрем тагын да начараеп китте. "Кинопленка"га кермәкче булам, алмыйлар - төнлә эшләргә кирәк икән, кондуктор итеп тә алмыйлар. Ии, мин бит авыл баласы, ник интегеп йөрим соң, дидем дә, бер яшелчә базасына барып, йөкче булып урнаштым. Шулай итеп эшле дә булдым. Казанга килгән өченче елны рабфакта укып, бөтен имтиханнарны да "биш"кә тапшырып укырга кердем. Нәкъ шул елны Казанда журналистика бүлеге ачылды.

Язгалап йөрим шулай "Социалистик Татарстан"га, ә үзем һаман йөкче булып эшлим. Минем тырышып йөрүемне күреп "Совет мәктәбе" журналының баш мөхәррире Фатих Ибраһимов, бу кыз килсен әле безгә, дип чакыртып алды. Очрашкач, әле эшкә алмыйм, сиңа чаклы гына университет бетергән кыз кереп чыкты, аны да алмадым, ди. Мин әйтәм, ярый, абый, рәхмәт, бик күңелле булды, дип чыгып киттем инде. Бу: "Карале, мин аңа эшкә алмыйм дип әйттем, ә ул миңа елмаеп, рәхмәтләр әйтеп чыгып китте", - дип уйга калган. Берничә ай узгач, мине тагын чакыртып, техник редактор итеп эшкә алды. Йөгереп кенә йөрдем инде цех белән редакция араларын! "Азат хатын" журналы мөхәррире Асия Хәсәнова да сынап карап торган икән, техник редактор итеп эшкә чакырды. Менә шулай итеп, 1962 нче елда мин чын журналистикага кереп киттем.

> ***"Журналист эзләнүчән, үткен, тәвәккәл, белемле, һәр яктан әзерлекле, кешеләр белән уртак тел таба белә торган һәм үз милләтенә хезмәт итәргә әзер булырга тиеш. Журналистны аяклары ашата" дигән гыйбарәне дә халык юкка гына әйтмәгәндер. Бу һөнәрне сайлагансың икән, битараф булма. Битарафлык журналистика өчен бик начар нәрсә.***

Яшь журналистларга киңәшем шул: мәктәп иншаларын "5"кә генә тапшыру, мәкаләләр язу, дикторлар кебек чибәр һәм матур тавышлы булу гына җитми шул әле. Журналист эзләнүчән, үткен, тәвәккәл, белемле, һәр яктан әзерлекле, кешеләр белән уртак тел таба белә торган һәм үз милләтенә хезмәт итәргә әзер булырга тиеш. "Журналистны аяклары ашата" дигән гыйбарәне дә халык юкка гына әйтмәгәндер. Бу һөнәрне сайлагансың икән, битараф булма. Битарафлык журналистика өчен бик начар нәрсә. Ә бүгенге яшьләрдә ул, кызганычка, бик көчле. Мин, яшьләр начар, дип әйтергә теләмим, битарафлык ул аларның саклану чарасыдыр, "миңа үзегезнең фикерегезне көчләп такмагыз, минем үз максатларым бар" дигән сүздер, мөгаен. Битараф булмау - кызыксыну ул. Ә кызыксынган кешенең үз фикере, әйтер сүзе була. Мәгълүмат туплау фикерләү сәләтен үстерә, кеше бар нәрсәне анализлый башлый. Журналист үзе анализлый белергә һәм язмасында укучы өчен дә анализларга җирлек тудырырга тиеш, - ди Әлмира апа.

Әле журналистикадан башка да ул бик күп эшләр белән шөгыльләнә. 1995 нче елда Татарстанда хатын-кызлар өчен Мөселман хатын-кызлары берлеге (хәзер "Мөслимә" дип атала) иҗтимагый оешмасын төзегән. Раббыбызның рәхмәте белән аның башлангычында инде 16 тапкыр "Сөембикә сеңелләре һәм энеләре" конкурсы үткәрелде. Чит төбәкләрдә һәм чит илләрдә үткәрелгән төрле корылтайларда Татарстаннан делегат булып катнашкан хатын-кыз ул Әлмира апа. Ә 2005 елны, барыбызны таң калдырып, планетаның мең хатын-кызы арасында Нобель премиясенә тәкъдим ителде. Татарларның мәнфәгатьләрен кайгыртып, түрәләргә бик күп хатлар язган, һәрвакыт үз максатына ирешкән кеше ул.

Паспортка яулык бөркәнеп фотосурәткә төшү өчен рөхсәт алулары гына да ни тора бит! Бу җәһәттән, Әлмира апа өенә дөньяның төрле кыйтгаларыннан кеше хокуклары белгечләре, журналистлар килә. Аллага шөкер, бик күп мәхкәмәләрдә булып, ниятләренә ирешәләр. Кол Шәриф мәчете иңкүлегеннән "Раки" сыраханәсен алдыру үзе бер хикмәт бит. "Сотворение мира" рок-фестивален туктатуда да аның өлеше бар. Дүрт ел буе аңлату, җитәкчелеккә мөрәҗәгатьләр... И-и андагы илереп-тилмереп йөрүләр!.. Шунысы сокландыра - ул беркайчан да, юлында нинди генә авырлыклар-киртәләр очраса да, башлаган эшен ярты юлда калдырмый. Безнең арабызда менә шундый мөслимә, менә шундый журналист яши (ул "Мөслимә" газетасының редакторы да). Мөхлисә Бубый варислары бар бездә, җәмәгать, аларны күрә белергә һәм, әлбәттә, алардан үрнәк алып, эшләрен дәвам итәргә кирәк.

Сөмбел ШӘРИФУЛЛИНА

Редакциядән. *75 яшен тутырган Әлмира апаның, сөбханалла, көч-куәте, дәрт-дәрманы ташып тора. Бүген дә дин дип, милләт дип чапкан көне. Без аңа исәнлек-саулык, бәхетле озын гомер, иҗат дәртенең сүрелмәвен телибез. Иншә Алла, шулай булыр. Үзе дә әнә җиңнәрне тагын да сызганыбрак эшләргә чакыра бит.*

"ҖИҢНӘРЕБЕЗНЕ ТАГЫН ДА СЫЗГАНЫБРАК ЭШЛИК"

Мөселман хатын-кызларының март аенда үткәреләчәк корылтаена әзерлек кысаларында Казанның Ярдәм мәчетендә абыстайлар җыены үтте. Аны "Мөслимә" иҗтимагый оешмасы рәисе Әлмира апа Әдиатуллина алып барды.

Мәҗлестә сүз гаилә, ата-аналарның вазыйфасы, балалар тәрбиясе турында барды. Ярдәм мәчете имам-хатибы Илдар хәзрәт Баязитов залдагы хатын-кызларны Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм үз исеменнән әлеге вакыйга - җыен уңаеннан котлады. "Бу мәҗлес - минем өчен шатлыклы вакыйга. Ярдәм мәчетендә нинди генә куанычлы хәл булмасын, безгә ул, Аллаһы боерса, савап булып язылыр. Сез барыгыз да төрле мәчетләрдә, мәдрәсәләрдә ислам нигезләрен укытасыз, яшьләребезне әдәп-әхлакка өйрәтәсез. Без дә динебезне күтәрергә, үстерергә тырышырбыз",- диде Илдар хәзрәт һәм сүзне мөфтинең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батровка бирде.

- Әгәр сезнең кебек тырышлык куючы кешеләр булмаса, халкыбызда ислам дине сакланып калмаган булыр иде. Шуның өчен сезгә олуг рәхмәтләребезне белдерәбез, - диде Рөстәм хәзрәт. - Соңгы вакытларда хатын-кызларның яулыктан йөрүе мәсьәләсе калыкты. Яшь татар кызларының әхлагы саклансын, тормышлары матур булсын дигән максаттан чыгып киелгән яулык бит ул! Әле күптән түгел генә югары уку йортында яулык киеп намаз укыган бер кызга карата тискәре караш күрсәтелгән, безгә ул низагны бетерү насыйп булды. Мөфти хәзрәтебез кызларның яулыгы, өс киеме турында Татарстан мәгариф министры белән очрашып сөйләште һәм мәсьәлә уңай хәл ителде. Гореф-гадәтләребезне саклап яшәргә безнең закон нигезендә хокукыбыз бар, - диде Рөстәм хәзрәт.

Мәҗлестә чыгыш ясаучылар күп булды. Рәшидә абыстай Исхакый, мөгаллимәләр һәм чакырылган кунак ханымнар Лена Таҗиева, Флера Ханнанова, Сәйдә Аппакова, Сәрия Зыятдинова, Кадрия Идрисова, Фәүзия Казыйханова, Разия Шакирова, Рида Мисбахова һәм башкаларның күркәм чыгышлары бераүне дә битараф калдырмады. Соңыннан, дилбегәне кабаттан үз кулына алып, Әлмира апа, абыстайларны җиңнәрне тагы да сызганыбрак эшләргә чакырды.

Хатыйп ГӘРӘЙ

Гарәп телендә "иман" сүзе ышану дигәнне аңлата. Ышану ул дөньялыктагы барлык кыйммәтләрдән дә кадерлерәк нәрсә. Чын күңелдән ышану белән чагыштырганда җир йөзенең байлыклары ком бөртеге генә. Иман - мәңгелек дөньяда коткарылуга ачкыч ул.

Иман

Бу очракта сүзнең теләсә кайсы дин турында түгел, ә бары хак дин - ислам дине турында баруын аңларга кирәк. Гадәттән тыш илаһи бер нәрсәгә генә ышану аз, дөрес ышанырга кирәк. Аллаларның күп булуына, изге өчлеккә яисә кеше җаннарының яңадан терелүенә ышануда мәгънә юк. Бу "ахмаклар алтыны". Мондый иман бер тиенгә дә тормый.

Бүгенге көндә исламны белүче кеше Аллаһы Тәгаләнең барлыгына ышанып та, үзен мөселманнардан санамаса, аның ышануы кабул ителми.

Ислам дине теләсә нинди алтыннардан да кыйммәтрәк. Мөселманнар - хак иман кешеләре. Иң фәкыйрь мөселман да мөселман булмаган иң бай һәм иң абруйлы кешедән өстенрәк.

Диндар кеше үзенең мәңгелектәге яшәеше турында кайгырта, ә имансызлар бу хакта уйлап та карамый. Аллаһы Тәгалә имансызлар турында Коръәни-Кәримдә болай дигән: "Алар дөньялыктагы яшәеш өчен нәрсә кирәген, ничек ләззәтләнергә икәнен беләләр. Ләкин алар ахирәттәге тормыш хакында хәбәрдар түгел һәм бу турыда уйлап та карамыйлар" ("Әр-Рум" сүрәсе, 7 нче аять).

Иманлы кеше узен Барлыкка китерүче Аллаһы Тәгаләгә табына, ә имансыз бәндә - Аллаһыга түгел, табигатькә һәм табигать күренешләренә, потларга, хөкемдарларга, үзенең дәрт һәм теләкләренә буйсына. Кеше кемгә яисә нәрсәгә дә булса табынмыйча тора алмый. Кайчакта кеше үзен бернигә дә, беркемгә дә буйсынмаганлыгына ышанган очраклар да бар. Ләкин бу дөрес түгел, чөнки ул кеше үзенә-үзе табынган була.

Бөек хөкемдарларның берсе үзенең тәкъвалыгы белән танылган мөселманга болай дигән: "Ни телисең, шуны сора: мин синең теләсә кайсы үтенечеңне башкарам". Мөселман: "Син минем колымның колы булганда, ничек синнән ни дә булса сорыйм инде", - дип җавап кайтарган. Хөкемдар аннан: "Мин бит бай кеше, ничек инде мин синең колыңның колы булыйм?" - ди. Тәкъва мөселман: "Син үз теләкләреңнең, дәртеңнең колы, ә мин үземнең дәртемне тыя беләм", - дигән.

Иманлы кеше өчен кулланма - иң Кодрәтле һәм иң Белемле Аллаһы Тәгаләнең Кануны. Имансыз кеше исә кешеләр уйлап чыгарган кануннарга буйсына. Кеше кануннары даими рәвештә үзгәреп тора һәм берберсенә каршы килә; бу бик ышанычсыз "кыйбла".

Акыллы һәм фикерле кешеләр иманны сайлый, ә ахмаклар динсезлектә адаша. Уйлана торгач, кеше Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә, Аның кимчелекләрдән саф булуына, пәйгамбәрләрнең Раббыбыз тарафыннан могҗизалар ярдәмендә җибәрелүенә инана. Ислам - акыл-фикергә өстенлек бирелгән дин һәм ышану акылга каршы килми.

ИМАННЫҢ АЛТЫ БАГАНАСЫ

1. Аллаһы Тәгаләгә ышану;
2. Аның фәрештәләренә ышану;
3. Аның китапларына ышану;
4. Аның илчеләренә һәм пәйгамбәрләргә ышану;
5. Ахирәт көненә ышану;
6. Тәкъдиргә, ягъни яхшының да, яманның да Аллаһы Тәгалә кушуы белән булуына ышану.

Әгәр кеше шушы кагыйдәләрнең берсенә генә булса да ышанмаса, аның иманы чын саналмый.

("ИСЛАМ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШИК" энциклопедиясеннән)

Иң хәерле сүз - Аллаһы Тәгалә сүзе, иң хәерле юл - Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) юлы. Безнең әби-бабайларыбыз дөньяда да, ахирәттә дә кешене бәхеткә, уңышка илтә торган туры һәм хак юлда булдылар. Динебезне төрле авырлыклардан, кимсетүләрдән саклап, саф көенчә безгә тапшырдылар. Бурычыбыз - бөтен яктан үрнәк, милләтебез горурланырлык, иман нуры, гыйлем нуры таратырдай шәхесләр тәрбияләү.

МИРАС ЧЫЛБЫРЫ ӨЗЕЛМӘСЕН

Арча районында 76 мәчет бар, шуларның 60 ында башлангыч дини белем бирелә. Мин үзем Арча станциясе мәдрәсәсендә укыту эшләрен оештыручы һәм мөгаллимә. Мәдрәсәбездә гыйлем бирү өчен барлык шартлар тудырылган. Сыйныф бүлмәләре техник җиһазлар белән җиһазландырылган. Мөгаллимәләребез "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә белем алган. 4 еллык программа буенча укытканнан соң, шәкертләребезгә шәһадәтнамә тапшырабыз. Дәресләребездә аять-сүрәләр ятлаганда компьютердан файдаланабыз. Үткәргән чараларны видеога төшереп барабыз.

Мәдрәсә гыйлем бирү генә түгел, тәрбия учагы да. Балаларның күңелләренә ислам әхлагын сеңдерү максатыннан кичәләр дә үткәрәбез. Хәдис, вәгазь кичәләре, хаҗилар һәм дин әһелләре белән очрашулар балаларның алган белемнәрен тагы да ныгыта дип саныйбыз. Төрле темаларга бәйге-конкурслар уздырабыз. Һәр елны район күләмендә уздырылган дини бәйгеләрдә катнашабыз. Казанда үткәрелгән "Сөембикә энеләре һәм сеңелләре" бәйгесендә призлы урыннар яуладык.

Җәй көне балалар өчен лагерь ачабыз. Туган җиргә мәхәббәт, табигатенә сакчыл караш тәрбияләү максатыннан алар өчен экскурсияләр оештырабыз. "Исәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен бел" дигән мәкальне девиз итеп алып, зиратка барабыз, караучысы булмаган каберләрне чистартабыз.

Мәчетебезнең ачылу датасы, беренче имамы, мөгаллимнәре, шәкертләре, үткәрелгән чаралар турында фотолар белән бизәп альбом төзедек. Башка мәхәллә мөгаллимнәренә дә тәкъдим итәм: мәчетегезнең тарихын таблица рәвешендә генә булса да теркәп куегыз. Үз төбәгебезнең мирасын, хәзинә, ядкяр сәхифәләрен тергезеп, аларны балалар күңеленә җиткерергә, динебезне балаларыбызга, оныкларыбызга мирас итеп тапшырырга насыйп булсын.

Рая ФӘТХУЛЛИНА,
Арча мөхтәсибәте

КОРЪӘН УКЫЛГАННАН СОҢ ДОГА КЫЛУ ТӘРТИБЕ

Әлхәмдүлилләәһи раббил гааләмииин вәссәләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил кәрим үә галәә әәлиһи үә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Йә, Рәхмәтле Раббым, укылган Коръән аятьләребезнең хата-кимчелекләрен гафу итеп, Үзеңнең киң рәхмәтең белән кабул кылсаң иде.

Укылган, тыңланган Коръән аятьләреннән, әйтелгән зикер-тәсбихларыбыздан хасил булган әҗер вә савапларны фани дөньядан мәңгелек ахирәткә күчкән иң камил кеше, барлык пәйгамбәрләрнең имамы булган, безне бәхетле булырга өйрәткән сөекле Рәсүлең Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәламнең рухына, атабыз Адәм галәйһиссәлам һәм анабыз Һәвадан алып бүгенге көнгә кадәр килгән бөтен пәйгамбәрләрнең, әүлияләрнең, галимнәрнең рухларына ирештерсәң иде. Шулай ук безнең догаларыбызга мохтаҗ булган газиз әти-әниләребезнең, әби-бабаларыбызның, дәү әти-дәү әниләребезнең, кыз һәм ир туганнарыбызның, (шул исәптән, догага мохтаҗ булган аерым әрвахларның исемнәрен әйтергә мөмкин) барча мөәмин-мөселман кабер әһелләребезнең, мәрхүм-мәрхүмәләребезнең рухларына ирештереп, аларның гөнаһларын, хата-кимчелекләрен гафу итеп, рухларын шатландырсаң иде.

Йа, Кодрәтле Раббым, аларның каберләрен нурландырып, хисапларын җиңеләйтсәң иде. Аларга Синең сөекле бәндәләреннән, җәннәт әһелләреннән булырга насыйп итсәң иде.

Йә, Рәхим-шәфкатьле Раббым, укылган намазларыбыз, әйтелгән зикер-тәсбихларыбыз, кылган игелекле гамәлләребез хөрмәтенә, белеп һәм белмичә кылган гөнаһларыбызны, хата-кимчелекләребезне, ялгышларыбызны Үзеңнең киң рәхмәтең белән гафу итсәң иде.

Йа, Раббым, һәрбарчабызга исәнлек-саулык, хәерле һәм бәрәкәтле гомерләр насыйп итсәң иде. Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз. Синең кушканнарыңны ихлас күңелдән үтәп, тыйган гамәлләреңнән тыелып, иксезчиксез рәхмәтеңә һәм ризалыгыңа ирешергә, ике дөньяда да бәхетле бәндәләреңнән булырга насыйп итсәң иде.

Һәркайсыбызны хәвеф-хәтәрләрдән, сугышлардан, ачлык хәсрәтеннән, сихерләрдән, табигать гарасатларыннан Үзең сакласаң иде.

Йә, Рәхмәтле Раббым, балаларыбызга, оныкларыбызга күркәм тәрбия биреп, алар өчен сөенеп, шатланып яшәргә, аларның игелеген, миһербанлыгын күрергә насыйп итсәң иде.

Йа Раббым, һәркайсыбызга бу дөньядан тулы иман, кальби сәлим белән китәргә, соңгы сулышларыбызда да: "Лаа иләәһә иллә ллааһу Мөхәммәдүррәсүлуллаһ", - дип әйтергә насыйп итсәң иде. Кыямәт көнендә сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең шәфәгатенә ирешеп, җәннәтләреңә керергә, Синең дидарыңны күрергә насыйп итсәң иде.

Вәссәләәтү вәссәләәмү галәә расүүлилләһ үә галәә әәлиһи үә әсхабиһи әҗмәгыйн.

ИШАН ХАТИБЫ

Гаилә мәчете ишекләрен ачкач, бөтен Азинога ямь иңде. Җомга җитсә дә, берәр бәйрәм чарасы булса да шунда барасы килеп тора. Хәзрәтләребез дә бик күркәм кешеләр, килгән һәркемне якты чырай белән каршы алалар. Хатип абый Бикмөхәммәтовка аеруча кадерхөрмәт күрсәтәләр биредә, аксакалның урыны һәрчак түрдә...

Хатип абый белән мин моннан алты ел элек "Шәһри Казан" газетасында эшләгән чагымда танышкан идем. "Җир алдым, Азинода мәчет төзибез",- дип йөрүе бераз мәзәгрәк тә тоелды ул чакта. Бу эшнең инициаторы булган эшмәкәр Мәхмүт Акберовны төрмәгә утыртып куйганнар, бабайның кулында бер тиен акча юк, алай да газетага белдерүләр урнаштырдык, язмалар әзерләдек. Авырлыклар күп булды, әмма ул һаман да Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә һәм игелекле кешеләрнең барлыгына ышанды. Инде менә бүген шушы гүзәл мәчет түрендә төзелешкә ярдәм кулын сузган игелекле бәндәләрне барлап утырабыз. Хәтерем начарайды дисә дә, ул кешеләрнең исемнәре, күпме акча биргәннәре - һәммәсе исендә: "Төзелешкә тотынганчы башта проект эшләтәсе бар бит, ә акча юк. Утырам шулай аптырап. Берзаман апалы-сеңелле Сания белән Гөлҗиһан апалар шалтырата. Мәчеткә үз өлешлә-рен кертәселәре килә икән, тик акчаны төзелеш башлангач кына бирәбез, диләр. Ул акчаларыгыз килде инде, Алланың рәхмәте булсын, кулыма гына кермәде, дим. Икенче көнне үк йөз меңсум китереп бирделәр. Кайсыберләре исемнәрен әйтмичә генә дә булышты. Аллаһы Тәгаләнең бәндәсенә дип дога кыла идек. "Мостстрой" җитәкчесе Айрат Әлмиев, "Мустаф", "ЖБК-сервис", "Промстройпроект" институты хезмәткәрләре, Әнис Таһиров, Ильбик Шәйдуллин... Яхшы кешеләр күп ул бездә. Илсур Метшинга Аллаһы Тәгалә исәнлек бирсен. Универсиада алдыннан килеп карап киттә дә, әллә ничә бригада эшче җибәреп, төзелешне санаулы көннәрдә тәмамлатып та куйды..."

... Туган ягында - Саба районы Олы Саурыш авылында аны ишан Хатибы дип йөрткәннәр. Шуны белгәч, исламга тартылуы балачактан ук киләдер дисәм, юк икән. "Ул кушамат әтием Бикмөхәммәттән күчте, - дип сөйләде Хатип абый. - Безнең әти яшь чактан ук бик тәртипле, юаш булган, кызлар белән йөрмәгән, өй тирәсеннән ерак китмәгән. Әнием Корбанбикә, киресенчә, кыю булган, күрәсең; әтине ошаткан да, ат җиктереп килен булып үзе килгән. Матур яшәделәр мәрхүмкәйләрем, әтиебез сугышта һәлак булды. Сугыштан соң тормышлар бик авыр иде. Күрше Төбәктә 7 класс тәмамлагач, колхозда эшли башладым. Авылда гына каласы да, салым бик зур. Әни пенсиядә ул вакытта. Әле тагын ике сеңелем бар. Берәр ел сукачы булып эшләгәч, киттем Казанга. Русча бер авыз сүз белмим, алай да төзүчелеккә укырга алдылар. Монда тормыш җайлашты, бушлай ашаталар, киендерәләр, йокларга тулай тораклта урын бар. Алты айда 4 нче разрядлы ташчы булып чыктым. Төзелешкә урнашып ике ел эшләгәч, армиягә алдылар. Кайтач та өйләнергә ашыкмадым әле, тагын ике ел йөрдем кызлар карап. Аннан инде Салиханы очраттым. Бик чибәр, сабыр иде ул. Иртәрәк үлеп китте шул менә, 71 яшьтә...Әлфиябез туугa бер барактан фатир биргәннәр иде. Шуны әйбәтләп ремонтладым, агарттым, түшәмен күтәрттем, мичен рәтләдем, мин миччe дә бит әле. Ай-яй Хатипның квартиры, дип карап йөрделәр күршеләр... Аннары инде гаилә ишәйде, Гүзәлебез туды. Яңа фатирга күчендек".

Пенсиягә чыккач, Хатип абый Казанның Мәдинә мәчетенә каравылчы булып урнаша, намаз укымый әле ул вакытта. Мин бөтенләй динсез түгел, диясе килде микән, шунда бала вакытта ук өйрәнгән "Әлхәм"не укып күрсәтә. Хатип абый, бу бит дөрес түгел, ди аңа Мәдинә мәчете имамы Гыйльмулла хәзрәт. Менә шуннан дөресләргә керешә инде. Әкренләп намазга баса, мәдрәсәдә Коръән укырга өйрәнә. "Әти олыгаеп килгәндә тырышып-тырмашып гарәпчә укырга өйрәнде, - дип сүзгә кушыла олы кызы Әлфия.- Әни әйтә, һай, булмас ул синнән, Хатип, ди. Әти, ник булмасын, була, Алла боерса, дип аның саен үҗәтләнебрәк тотына. Бер-ике елдан соң җәмәгать намазын алып барырга куша башладылар". Хатип абый үзе ул кыенлыкларны әллә ни исенә төшереп тормый. "Алладан вакыт җиткәч, үзеннән-үзе килеп чыкты, - ди ул.- Тик менә яшьли аралашып йөргән дусларым гына "тегендә" намазсыз китеп барды..."

Нәүбәһар КӘБИРОВА

ДОГА КЫЛГАЧ, АВЫРЛЫККА ЮЛЫКСАҢ...

Күптән түгел Аллаһы Тәгаләдән мал сорап, җиңеллек сорап кылган догасына җавап ала алмый гаҗизлеккә төшкән мөселман егетенең галимнәргә язган сорауахатын укырга туры килде: "Мин бик күп дога кылдым һәм күп яхшылыклар эшләдем, Аллаһ алдында гөнаһларымнан ихлас тәүбә иттем, Аллаһтан минем хәсрәтемне һәм тынычсызлыгымны бетерүен сорадым. Әмма дога кылып башлаган барлык эшләр җимерелеп төште һәм минем проблемаларым артты гына... Бу инде күптәннән бара һәм мине төшенкелек биләп алды, йөрәгемә шик үрмәли башлады. Әгәр Аллаһ үзүзеңне үтерүне тыймаса, мин үземә кул салган булыр идем..."

Без, мөселманнар, дога - мөәминнең коралы, дибез һәм Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп эндәшкән һәр сүзебезнең, күңелгә килгән һәр уебызның Аның тарафыннан ишетелүенә һәм шарты үтәлгән ихлас догага җавап булачагына ышанабыз, чөнки Раббыбызның вәгъдәсе бар: "Дога кылыгыз, кабул итәрмен" (Коръән, 40:60). Мөәминнәрнең әмире Гомәр ибн әл-Хаттаб та (Аллаһ аннан риза булса иде): "Мин доганың җавабы өчен аз гына да борчылмыйм, әмма мине дога үзе борчый. Әгәр күңелемә дога кылу нияте салынган икән, мин беләм: дога белән бергә җавап та булачак", - дигән.

Әмма без бер нәрсәне истә тотарга тиешбез: куллана белмәсәң, корал үзеңә атарга мөмкин. Шуңа күрә дога кылганчы, башта гыйлем алырга, доганың шартларын, аңа җавапның ни рәвешле булырга мөмкин икәнлеген өйрәнергә кирәк. Гарри Поттерлар турында әкиятләр укып, фантастик кинофильмнар карап үскән буын доганы әфсен белән бутый, Аллаһы Тәгаләгә эндәштең дә дөньяң шундук үзгәрде: мал сорасаң - мал килде, сәламәтлек сорасаң - саулыкка ирешәсең, дип уйлый. Аллаһы Тәгаләнең хикмәте белән кайвакытларда алай да булырга ихтимал. Әмма күпчелек очракта Ул үзенә мөрәҗәгать иткән адәм баласын сыный, аны Үз нигъмәтләрен кабул итәргә әзерли. Әгәр син сораган нәрсә, синең өчен зыянлы булса, җавапны кичектерергә, ахирәткә үк калдырырга да кодрәте җитә. Менә шушы сынау этабында адәм баласының күңеленә шайтан вәсвәсәсе үрмәли башлый да инде: төшенкелек, өметсезлек хисләре уятып, Аллаһы Тәгаләгә ышанычын юк итәргә тырыша, хәтта үз-үзенә кул салырга өнди. Ә бит теләгән нәрсәләребез күпчелек очракта безнең өчен зыянлы булып чыга. Аллаһы Тәгалә Коръәндә бу хакта да искәртә: "Әгәр Аллаһ һәр кешегә ризыкны киң кылып, һәрберсен бай итсә, ул вакытта, әлбәттә, һәркайсы җир өстендә бозыклык һәм фәсәд кылыр иде, шуның өчен кешеләргә малны Үзе теләгәнчә генә бирәдер. Аллаһ, әлбәттә, кешеләрнең хәлләреннән хәбәрдар һәм кемгә киң ризык тиешле, кемгә тар тиешле икәнен дә белүчедер" (Коръән, 42:27).

Бу дөньяда файдалы байлыкка ирешү юлы катлаулы. Пәйгамбәр (с.г.в.) бу хакта: "Кем ахирәт тормышын кайгырта, шуны Аллаһы Тәгалә күңел байлыгы һәм булышчылар белән бүләкли, ә дөнья нигъмәтләре аңа үз теләгенә карамастан килә. Ә кем бу дөньясы өчен борчыла, аның күз алдында һәрвакыт фәкыйрьлек тора. Аллаһ аны ярдәмчеләрдән мәхрүм итә, һәм ул тәкъдирендә күпме язылган булса, шулкадәр дөнья малына ия була",- ди. Хәсән әл-Басри дигән мөселман галиме: "Дөнья тормышын ахирәтең өчен сат һәм син бу дөньяга да, ахирәткә дә ирешерсең. Әмма ахирәтеңне дөньяң өчен сатма, югыйсә икесен дә югалтырсың",- ди. Тәкъвалыкның югары дәрәҗәсенә ирешкәндә, адәм баласы күңелен шөкер белән тутыра. Шөкер исә тарлыкта да, киңлектә дә Аллаһы Тәгаләне мактаудан гыйбарәт, ягъни уңышсызлык килеп, авыр булганда да, әлхәмдүлилләһ, дип йөрәгең белән риза буласың, чөнки авырлыклар да Аллаһы Тәгаләнең нигъмәте - аның әҗере бар; уңышка ирешеп, ләззәткә юлыксаң да шуны ук кабатлыйсың. Бу дәрәҗәгә җитеп шөкер итүчеләр сирәк була, шуңа күрә адәм балалары даими стресста яши, ягъни бу дөньяларын да, ахирәтләрен дә югалта. Аллаһы Тәгалә исә депрессия кичерәсе урынга шөкер итүчеләргә: "Әгәр шөкер кылсагыз, әлбәттә, нигъмәтләремне арттырырмын", - дип вәгъдә бирә (Коръән, 14:7). Җиңеллек сорап дога кылгач, Аллаһы Тәгаләдән сынау булып авырлыклар килә башлау - бик табигый нәрсә. Аңлаган кешегә ул авырлыклар Аллаһы Тәгалә җавабының башы инде. Адәм баласы бу очракта шөкер итеп, ахирәте өчен әҗерле була, Аллаһы Тәгаләнең бу дөньяда биргән нигъмәтенә ирешә.

... Бер кораб батып, бәндәләрнең берсен дулкыннар кеше яшәми торган утрауга чыгарып ташлаган, ди. Ул көн саен җаны-тәне белән Аллаһы Тәгаләдән үзен коткаруын сорап дога кыла һәм көн саен офыкны күзәтә. Коткаручылар күренмәгәч, ярга чыккан бүрәнәләрдән үзенә кечкенә генә куыш әмәлли. Беркөнне ризык эзләп киткәч кайтса, күрә: яшеннән ут кабып, куышы янып бетеп ята. "Я, Раббым, мин синнән шуны сорадыммыни?" - дип үксеп егыла ул. Ә иртән ярга кораб якынлаша һәм аны коткаралар. "Сез минем монда икәнне каян белдегез?"- дип сорый ул коткаручылардан. "Син яккан учакның төтенен күрдек", - диләр тегеләре. Аллаһы Тәгаләдән җиңеллек сорап дога кылгач, авырлыкка юлыксагыз белегез: авырлык артында котылуның башы булырга мөмкин.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ,
филология
фәннәре кандидаты



Балалар - Рәхимле Раббыбызның бүләге ул. Аларны әманәт - сиңа вакытлыча саклауга ышанып тапшырылган әйбер буларак кабул итәргә, сакларга, аларга йомшаклык һәм хикмәт белән караргa кирәк. Ә Аллаһ ризалыгы өчен балаларга мәхәббәт билгесе булып синең аларны Аллаһ Илчесенең (с.г.в.) нәсыйхәтләре белән тәрбияләвең тора. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткән: "Әти кешенең баласына карата өч бурычы бар: бала туганнан соң аңа яхшы исем бирү, Коръәнгә өйрәтү һәм балигълыкка җиткәннән соң өйләндерү яки кияүгә бирү".

Балаларга һәм тормыш иптәшенә карата МӘХӘББӘТ

Моңа тарихтан бер мисал карыйк. Гомәрдән (Аллаһ аннан разый булса иде) тапшырылган, аңа үзенең улы белән бер кеше килеп: "Хакыйкатьтә, улым миңа карата начар гамәлләр кыла", - дигән. Гомәр (Аллаһ аннан разый булса иде) малайга болай дигән: "Әллә син әтиеңә карата гөнаһларың өчен Аллаһның ачуыннан курыкмыйсыңмы?" Әлеге кешенең улы әйткән: "Ий, хак мөселман туганым, улының әтисе алдында хокуклары бармы соң?" Гомәр (Аллаһ аннан разый булса иде) җавап биргән: "Әйе, бар. Улына күңелсезлек китермәс өчен, әти кеше малаен кимсетергә тиеш түгел, ягъни ул түбән чыгышлы хатын-кызга өйләнергә тиеш түгел". Аннары Гомәр (Аллаһ аннан разый булса иде) болай дигән: "Әти кеше малаена яхшы исем бирергә һәм аны Коръәнгә өйрәтергә бурычлы". Әлеге кешенең малае әйткән: "Аллаһ белән ант итәм, минем әтием әниемне кимсетте. Ул аны Синд шәһәреннән дүрт йөз дирһәмгә сатып алды. Әтием миңа яхшы исем бирмәде, мине "аңгыра" дип атады һәм Аллаһ Китабының бер генә аятенә дә өйрәтмәде". Гомәр (Аллаһ аннан разый булса иде) аның әтисенә караган да болай дигән: "Син малаем мине кыерсыта дисең, әмма, хакыйкатьтә, үзең гөнаһ кылгансың. Миннән чыгып кит".

Тормыш иптәшеңә карата да мәхәббәт булырга тиеш, чөнки ул Мәрхәмәт иясе булган Аллаһтан назлы бүләк булып тора. Нинди генә очракта да сөюеңне аның тиз уңа торган матурлыгы белән бәйләмә. Хакыйкатьтә, хатын-кызда иң күркәм як - аның йомшаклыгы, кайгыртучанлык күрсәтү сәләте, нәзакәтлелеккә илтүче ягымлы холкы һәм аңа хас гүзәллек бар. Ә аның иң кыйммәтле дәрәҗәсе - бөек, җитди, эчкерсез һәм шатлыкларга уралган рәхимлелеге. Һәм әлеге сокландыргыч рәхимлелек һәм шәп холык тормышның азагына кадәр дәвам итә һәм арта бара. Һәм әлеге сөю аның күркәм холкында нигезләнгәнлектән, син тормыш иптәшеңә карата саф мәхәббәт хисләре һәм рәхимлелек күрсәтәсең, ә ул үз чиратында сиңа ихтирам һәм үзара ярату белән җавап бирәчәк. Аның мөлаемлыгына һәм бик яхшы сыйфатларына корылган сөю еллар узган саен арта барачак, һәм сез картайганчыга кадәр әлеге мөнәсәбәтләр сезнең арагызда ныгыячак. Киресенчә булганда, ягъни ярату нәфескә бәйле булса, бары аның тышкы матурлыгына гына игътибар ителсә, мондый мәхәббәт уты тиз сүнәчәк, һәм сезнең үзара бик яхшы мөнәсәбәтләрегез юкка чыгачак. Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә: "...Хатыннарыгыз сезнең киемегез кеби, сез дә аларга кием (бөркәвеч) кебидер..." ("Бәкара (Сыер)" сүрәсе, 187 нче аять).

Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН

МАТУР БУЛУНЫҢ ҖИДЕ СЕРЕ

Мөслимәләргә матурлыкларын сакларга ярдәм итә торган борынгыдан килгән ислам традицияләре барлыгын сез беләсезме?

1. Сөрмә - табигый күз буявы. Сөрмәдән ясалган карандаш күз төпләренә агып төшми, аллергия бирми. Ул күзләрегезнең матурлыгын ассызыклаячак, карашыгызны тагын да серлерәк итәчәк. Әмма сатып алганда аның составын яхшылап тикшерергә онытмагыз.

2. Кына - порошок яки паста хәленә китерелгән үсемлек. Аның белән чәч, тырнак буйыйлар, кулларга бизәкләр төшерәләр. Хәзер туй алдыннан кәләшнең тәненә төрле матур бизәкләр төшерү модада. Күп кенә җитештерүчеләр кына дип составында төрле зарарлы матдәләр булган буяулар тәкъдим итәләр, сак булыгыз.

3. Матурлыкның тагын бер сере суда. Моннан мең ярым ел элек тә гарәп чүлләрендә Пәйгамбәребез еш юынырга кирәклек турында әйткән.

4. Зәйтүн мае организм өчен бик файдалы. Аны, коенып чыкканнан соң, крем урынына да файдаланырга киңәш итәләр. Ул тән тиресен яшәртеп җибәрә, тырнакларны нык ыта, чәчне йомшарта.

5. Һәр намаз алдыннан мисвәк кулланган кешеләрнең тешләре ак һәм таза була.

6. Хушбуй. Мөслимәләр ирләрен җәлеп итәр өчен һичшиксез хушбуй кулланырга тиеш. Хуш исле майлар мөслимәләр арасында бик популяр, чөнки аларның составында спирт юк, исе дә озак саклана.

7. Мөслимә шифалы, хәләл ризык ашарга һәм тәртипле тормыш алып барырга, Аллаһы Раббыбыз әманәт итеп биргән сәламәтлеге турында кайгыртырга тиеш.

СӨЙДЕРГЕЧ БОЗЫМЫН ДӘВАЛАУ

Күп кенә аңгыра хатыннар, сихерчеләргә барып, үз ирләренә сөйдергеч ясаталар. Ул сихерчеләр аларның ирләрен үзләрен сөяргә мәҗбүр итәчәк дип уйлыйлар. Ләкин алар бу эшнең хәрам икәнлеген уйлап та карамыйлар. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткән: "Мәгънәсе булмаган яки мәгънәсе аңлашылмаган сүзләргә сыену, күз тимәсен өчен, шуның өчен, моның өчен дип теләсә нәрсәләр асып бәйләп куюлар һәм ирләр каршында сөекле булу уе белән хатыннар тарафыннан шундый нәрсәләр ясатулар барысы да ширек булалар".

Ә кешеләрнең җаннары белән хакимлек итү бер Аллаһ кулында. Шулай булса да Аллаһның теләге белән сихер кешегә тәэсир итәргә мөмкин. Шул вакытта ир кешедә хатынына нык тартылу, көчле мәхәббәт, аны шашып күрәсе килү теләге , ансыз бер минут та тора алмау, хатынына сукырларча буйсыну һәм башка тойгылар пәйда була. Ләкин мондый бозымның ахыры хәерсез бетәргә, ул ир кешене бөтенләй эштән чыгарып ташларга мөмкин.

1. Ул шул бозым аркасында нык чирләргә мөмкин. Бер кешенең өч ел буена чирләп яту очрагы билгеле.

2. Киресенчә, ул хатынын күралмый башларга мөмкин.

3. Кайбер очракта ул хатынына тартылса да, башка бөтен хатын-кызларны, шул җөмләдән, әнисен, апа-сеңелләрен дә күралмый башларга мөмкин.

Бер очракта ир үз хатынын да, башка бөтен хатын-кызларны да күралмый башлый. Хатын эшне төзәтергә дип янә сихерчегә барса, ул инде үлгән була.

Бозымны чыгару өчен авыруга түбәндәге аятьләрне укырга кирәк:

"Фатиха" сүрәсе;

"Бәкара" сүрәсенең 1-5 , 163-164, 255, 285-286 нчы аятьләре;

"Әли Гыймран" сүрәсенең 18-19 нчы аятьләре;

"Әнгам" сүрәсенең 54-56 нчы аятьләре;

"Әграф" сүрәсенең 117-122 нче аятьләре (аларны берничә мәртәбә кабатларга);

"Юныс" сүрәсенең 81-82 нче аятьләре (берничә мәртәбә кабатларга);

"Та Һа" сүрәсенең 69 нчы аяте (берничә мәртәбә кабатларга);

"Мүэминун" сүрәсенең 115-118 нче аятьләре;

"Саффәт" сүрәсенең 1-10 нчы аятьләре;

"Әхкаф" сүрәсенең 29-32 нче аятьләре;

"Рахмән" сүрәсенең 33-36 нчы аятьләре;

"Хәшер" сүрәсенең 21-24 нче аятьләре;

"Тәгабүн"сүрәсенең 14-16 нчы аятьләре;

"Җен" сүрәсенең 1-6 нчы аятьләре;

"Ихлас" сүрәсе (берничә мәртәбә кабатларга);

"Фәләкъ" сүрәсе (берничә мәртәбә кабатларга);

"Нәс" сүрәсе.

Хасса бинт Рашид бине Габдуллаһ әл-Мәзәнинең "Коръән белән шифа табу" китабыннан

ҖИР ЙӨЗЕНДӘ ШӘФКАТЬЛЕЛЕК БАР

Берәүнең исән чагында биргән бер дирһәм сәдакасы үлгән вакытында биргән мең дирһәм сәдакасыннан хәерлерәк

(Хәдис)

Мин яшәгән подъездның бишенче катында бер ялгыз карчык яши. Биш ел элек аның ире вафат булды, ә ике ел элек кызы ире һәм ике баласы белән автоһәлакаткә очрады... Беркөнне универдан кайтып барышлый подъезд ишегенә кулдан язып эленгән белдерүгә күзем төште. Анда: "100 сум акчамны югалттым, тапсагыз, зинһар өчен, 76 нчы фатирга кертегез, ипи алырга да акчам юк", - диелгән иде. 76 нчы фатирда теге әби яши. Мин акча янчыгымнан йөз сумлыкны алдым да бишенче катка күтәрелдем. Акчаны әбигә сузганда ул елап җибәрде: "Син - миңа акча китерүче уникенче кеше. Рәхмәт". Мин елмаеп лифтка таба атладым. Шул чакта ул: "Кызым, алып ат ул белдерүне, аны мин язмадым",- диде.

Моны нәрсә өчен яздыммы? Җир йөзендә бар ул шәфкатьлелек, бар - шуны гына җиткерәсем килде.

(Социаль челтәрдән)

ТАҖ МАҺАЛ – МӘҢГЕЛЕК МӘХӘББӘТ СИМВОЛЫ



2007 нче елда Португалия башкаласы Лиссабон шәһәрендә "дөньяның 7 могҗизасы" игълан ителә. Ул исемлектә Аградагы (Һиндстан) мәшһүр мәчет-төрбә - Таҗ Маһал да бар.

Таҗ Маһалның тарихы - моголлар императоры Шаһ-Җиһанның хатыны Мумтаз Маһалга булган мәхәббәт тарихы. Принц Шаһ-Җиһан 19 яшьлек чибәркәйгә өйләнә. Ул хатынын шулкадәр ярата ки, зур гаремы булса да, бөтен назын һәм игътибарын бары тик Мумтазга гына бирә. Мумтаз аңа 14 бала - алты кыз һәм сигез угыл таба. Әмма соңгы баласын тапканда үлеп китә. Шаһ-Җиһан хәсрәткә бата, яшәвенең мәгънәсен югалта, чалара, хәтта үз-үзенә кул салырга тели. Хатыны истәлегенә аның кабере өстенә ул бик матур Таҗ Маһал сарае төзетә, берничә елдан соң аның үзен дә шунда - хатыны янәшәсенә җирлиләр. Таҗ Маһал - дөньяның могҗизасы гына түгел, мәңгелек мәхәббәт символы да.

Таҗ Маһал - моголлар архитектурасының иң күренекле үрнәге. Ул фарсы, һинд һәм ислам архитектурасы стильләрен берләштерә. Аны шулай ук "Һиндстан мөселман сәнгатенең энҗе бөртеге" дип тә атыйлар. Ак мәрмәр гөмбәзе иң мәшһүр элементы булса да, Таҗ Маһал - структур комплекс. Бина эчендә ике төрбә урнашкан. Аның кыйммәтле ташлар белән бизәлгән ак мәрмәр диварларына Коръән аятьләре язылган. Мәрмәр гөмбәзенең биеклеге 35 метр. Ә мәчет үзе 74 метр биеклектә, дүртәр манаралы биш гөмбәзле. Сарай 1631 нче елда төзелә башлап, 22 елдан соң гына төгәлләнә. Аны төзүдә 20 мең кеше катнашкан, төзү материалларын ташуда меңнән артык фил һәм үгезләрдән файдаланганнар.

1983 нче елда Таҗ Маһал ЮНЕСКО Халыкара мирасы объекты булып игълан ителә. Мәчетне карарга көн саен төрле илләрдән миллионнарча турист килә. Аның ишекләре җомгадан кала барлык көннәрне дә ачык.

ИСЛАМ ТУДЫРГАН МАТУРЛЫК

Пью үзәгенең яңа мәгълүматларына караганда, 2030 нчы елга Мексикада 126 мең мөселман яшәячәк, 2010 нчы елда аларның саны 111 мең булган. Мексикада биш гасыр буе католик дине өстенлек итсә дә, аларның саны 96,7 процеттан 82,7 процентка кадәр кимегән. Бу үзгәрешләр халыкның акрынлап башка диннәргә күчә баруы, аерым алганда, ислам динен кабул итүе бәрабәренә булган. Мексикалыларның исламга күчүләренең сәбәпләрен ачыкларга тырышкан Уильям Шефер (GlobalPost): "Сәбәпләр төрле. Берләре исламны бер иләһлык өчен сайласа, икенчеләренең чиркәүдәге сексуаль гаугалардан гайрәте чиккән. Өченчеләрнең исә исламны яхшырак аңлыйсылары килә", - ди.

23 яшьлек Марта Аламилья католиклар гаиләсендә туып үскән. "Аллага һәрвакытта да ышана идем. Әмма мин элек тоткан диндә мәгънәсе булмаган нәрсәләр бар. Бу турыда сорау биргәч, "чөнки Алла шулай дигән" кебек җавап ала идем",- ди Марта. Шушы җаваплар аны чиркәүдән читләштергән дә инде. Кыз әйтүенчә, исламны ул элек террорчылык белән генә бәйләп кабул иткән, Коръән укый башлагач, мөселманнар белән якыннан аралашкач, ул үзен борчыган барлык сорауларга да дәлилле җавап тапкан. "Ислам - матур дин. Коръәндә һәм Сөннәттә барлык сорауларга да җавап бар. Мин очраткан мөселманнар - искиткеч кешеләр. Аларны ислам шулай матур иткән", - ди ул.

КАМАЛ САЛИХ YOUTUBEНЫ "ШАРТЛАТТЫ"

22 яшьлек Камал Салих Австралиянең Панчбоул шәһәрендә яши. Ул яшьтән үк сәнгатькә тартылган, сүз сәнгате таланты аны YouTubeтагы роликлары аша миллионнарча тамашачыга танытты. Аллаһ рәхмәте белән, Камал исламны яңа форматта - сәнгати декламация жанрында уңай яктан күрсәтүгә ирешә. Аның "Мәхәббәт, никах һәм әкият" дигән поэмасы гаиләне һәм гаилә кыйммәтләрен саклау проблемасына багышланган. Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.) турындагы поэмасында Камал Салих сөекле Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) гаҗәеп холкы турында сөйли. Камалның чыгышларына битараф кала алмаган тамашачылар интернет челтәрендә үзләренең тәэсирләре белән бүлешәләр, авторга чиксез рәхмәтләрен җиткерәләр.

Әлеге жанрда эшләүче сәнгать осталары хәзер бик күп. Әмма Камал Салих - декламация жанрын дәгъвәт дәрәҗәсенә күтәргән бердәнбер башкаручы. Үзенең ихласлыгы белән ул мөселманнарны гына түгел, башка диннәр вәкилләрен дә җәлеп итте. Ислам өчен җан атып торган бу сөйкемле мөселман егете үтә тыйнак та - аның Твиттер аккаунтында нибары бер фото куелган. Яшь, бөтен көчен җәмгыятькә файда китерүгә түгүче Камал Салих 2012 нче елда Австралия мөселманнары арасында зур бүләккә лаек булган -"Ел башкаручысы" номинациясендә җиңү яулаган.

ТӨРЕК КЫЗЫ ДӨНЬЯ МӨСЕЛМАННАРЫ ХОКУКЫН ЯКЛЫЙ

"Без - яшьләр идарә итеп булмый торган маргинал дөньяда яшәргә теләмибез, ә тигез хокуклы булып, тынычлыкта яшисебез килә",- дип белдерде Зөһрә Сарыаслан Берләшкән Милләтләр Оешмасының чираттагы утырышында. Голландия яшьләр хәрәкәте вәкиле, төрек Кызы Зөһрә моннан элек тә - узган елных октябрендә БМО утырышында әбисенең язмышы турында сөйләп, алкышларга күмелгән иде. "Яшьләргә милли, җенси, социаль һәм башка төрле кысалар белән чикләнмәгән гадел һәм тыныч дөнья төзергә мөмкинлек бирергә кирәк. Хатын-кызлар һәм яшьләр киләчәкне төзүдә катнашу мөмкинлеге алмыйча үзара аңлашу һәм тынычлык булмаячак", - ди Зөһрә.

Аның планнары зурдан. Быелның маенда ул Коломбода узачак халыкара яшьләр конференциясендә Голландия вәкиле буларак катнашырга җыена. Аңарчы Эшчеләр партиясеннән Голландиянең җирле муниципалитетына депутат булып сайланасы бар әле. 22 яшьлек бу мөслимә алдынгы мөселман яшьләренә үрнәк булып тора. Бүген ул мөселманнарның, хатын-кызларның һәм яшьләрнең хокукларын яклауда актив катнаша.

СУ ТӨБЕННӘН ЗИРАТ КАЛКЫП ЧЫКСА...

Быелгы корылык аркасында Төркиянең байтак сусаклагычлары саеккан. Кайберләрендә су минималь билгегә җиткән. Су запасы берничә айлык кына калган торак пунктлар да бар. Адана өлкәсендәге Сейхан сусаклагычында да хәлләр шәптән түгел икән. Су яр буеннан 500 метрга чигенгән һәм кайчандыр су астында калган авыл урыннары шәйләнә башлаган. Хәтта 1956 нчы елдан бирле су астында яткан Топалак авылы зираты да калкып чыккан. Хәзер якын-тирә авыллардан халык бирегә туганнары каберләрен зиярәт кылырга йөри ди.

Сәхифәдә http://islam-today.ru/ порталы материаллары файдаланылды

Абд ар-Рахим әл-Идриси: «Ызгыш һәм фенәдән сак булыгыз»

Абд ар-Рахим әл-Идриси Морокконың Мекнес шәһәрендә дини гаиләдә туып үскән, шәригать, фикыһ һәм сира фәннәре белгече. Аның нәсел тамырлары Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә барып тоташа. Татарстан мөселманнары Дония нәзарәте һәм шәхсән мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин чакыруы буенча безнең республикага визиты вакытында "Азан"радиосына интервью биреп, ул татарлар турындагы фикерләре белән дә бүлешкән иде.

Абд ар-Рахим әл-Идриси Казанда беренче тапкыр 2012 нче елда була. Сәфәрдән кайткач, студентларына татарларның асылы һәм тамырлары - ислам, дип сөйли. Фикерләрен: "Мароккода яңгыр яуганда мәчеткә фарыз намазына кеше килми, ә Татарстанда мин шуның шаһиты булдым: егерме градуслы суыкта мәчет яшьләр, картлар белән тулды", - дип дәлилли.

Аннары ул "гарәп язы"на туктала: "Гарәп илләрендә барган кризисны "гарәп язы" дип атап булмый, бу күбрәк көзгә охшаган. Яз җимешләр бирергә тиеш, ә бу инкыйлаблар бернинди җимеш тә, нәтиҗә дә китермәде. Мин Сүриядә яшәдем һәм низагның ничек башланып китүенең шаһитымын, берничә тапкыр Мисырда да булдым. Моңа кадәр Сүрия һәм Мисыр халкы куркынычсыз дөньяда яши иде, әмма алар "азатлык" һәм власть алышынуын теләде. Үзгәрешләр, кызганычка, яхшыдан яманга булды. Хәзер Сүрияне аякка бастыру өчен ике гасыр, ә Мисыр халкына өч гасыр кирәк булачак. Сез, Аллага шөкер, тыныч лыкта яшисез. Бер-берегез белән аңлашу, хөкүмәтегез һәм президентыгыз белән хезмәттәшлек аша бу тотрыклылыкны саклагыз. Алга киткән һәм нык дәүләт шундый диалог нигезендә төзелә.

Ызгыш һәм фетнәдән сак булыгыз, бөтен җирдә дә Татарстандагы кебек тыныч һәм бәхетле яшәмиләр. Бүген чын ислам тынычлыкны, куркынычсызлыкны, мәхәббәт һәм үзара ярдәмләшеп яшәүне юксына. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.): "Кемнең теле белән кулыннан мөселманнар иминлек таба, шул - мөслим кеше" - дигән.

«Халифәт шаһитларының» биш хәйләсе

Бер фәнни-тикшерү институты хезмәткәре һәм Islam-today.ru порталы консультанты Дмитрий Хәлилов Россиядә тыелган "Хизбүт-тәхрир" оешмасы әгъзаларының башкаларны үзләренә җәлеп итәр өчен нинди хәйләләр коруы турында сөйләде:

1. "Хизбүт-тәхрир" әгъзаларының үз оешмаларына тарту ысуллары турында бүгенге көнгә берничә тикшерү үткәрелде. Мәсәлән, психология буенча бер белгеч бу ысулларда кешенең миен "туңдыру" һәм "туңдырылган халәтеннән чыгару" кебек терминнарны үз эченә алган психологик методика һәм технологияләр барлыгын ачыклаган. Бу оешма тарафдарлары кеше аңы белән манипуляцияләр эшләү технологияләрен алар өчен кирәкле кешеләр белән шәхси әңгәмәләрдә дә, интернет хат алышуларда да, үзләренең медиапродукцияләрендә дә кулланалар. "Хизбүт-тәхрир" әгъзалары кулланган методикалар башка дини агымнарда да, мәсәлән, "Йәһвә шаһитлары" оешмасында кулланыла. Бәлки, нәкъ менә шуңа күрә беренчеләрен "Хәлифәт шаһитлары" дип атый башлаганнардыр да. Аерма шунда гына - "Хизбүт-тәхрир"дә бу методика ислам кабыгына төрелгән һәм ислам төсенә буялган.

2. Дин күзлегеннән караган вакытта, бу агым тарафдарлары, кагыйдә буларак, үз әңгәмәдәшләрен башта төрле аять һәм хәдисләр белән таң калдырырга тырыша, мәсәлән, алар шундый хәдисне китерергә ярата: әгәр дә кеше әмиргә (хәлифәгә) ант итми генә үлеп китсә, ул - җаһилият заманында үлгән кеше. Җаһилият - ислам кабул иткәнгә кадәрге, денсез, имансыз чор, димәк, җаһилият заманында үлгән кеше - зур гөнаһлары белән үлгән кеше булып чыга. Моны ишеткән мөселманнарның беркатлырагы аннан: "Ничек итеп мондый тәкъдирдән котылырга?" - дип сорый торгандыр инде. Шул вакытта алар бу мөселманга әмирләренә ант итәргә тәкъдим итәләр. Әлбәттә, турыдан-туры түгел, ә бу оешманың җирле вәкилләре аша. Кызганычка, мондый пропаганда еш кына уңышка да ирешә. Шундый ант биргән вакытта кеше Аллаһы Тәгалә исеме белән ант итә. Бу ант текстында, мәсәлән, бу кеше әмирнең бар әмерләрен дә берсүзсез үтәргә ант итә, гәрчә ул аларның асылын аңлап бетермәсә дә. Әлбәттә, бу хәдиснең кайчан, ни өчен әйтелгән икәнлеген аларга беркем дә аңлатып тормый. Алар кешене факт алдына куялар һәм аңа мондый хәлдән чыгу өчен "ачык күренеп торган юл" тәкъдим итәләр. Әмма ислам дине галимнәре, бу хәдис тәкъва хәлифәләр чорына карый, дип аңлаталар, хәзерге вакытта исә, алар фикеренчә, бар мөселманнарның да уртак бер дәүләте булган хәлифәт юк, шуңа күрә мөселман шул булган хәлифәгә ант итәргә һәм аның каршында үзенә ниндидер йөкләмәләр алырга бурычлы түгел.

3. Моннан тыш "Хизбүт-тәхрир" вәкилләре пропаганда максатларында кайбер аятьләрне дә кулланалар. Алар бу аятьләрне үзләренчә аңлатырга тырышалар. Мәсәлән, "Әли Гыймран" сүрәсендәге бер аятьнең мәгънәсе шундый: "Сезләрдән арагызда шәригатьне яхшы белгән кешеләр, әлбәттә, булсын! Алар сезне хә-ерле эшләргә чакырырлар, фарыз гамәлләрне, башка яхшы эшләрне кылырга әмер бирерләр һәм фәхеш, хәрам эшләрдән вә бидгать гамәлләрдән каты тыярлар. Әнә шундый җитәкчеләре булган җәмәгать һәлак булудан котылып, өстенлек табучыдыр". Күп кенә агымнар бу аятьне үзләренә багышланган дип аңлаталар, "Хизбүт-тәхрир" дә искәрмә түгел. Алар андый кешеләр төркеме җәмгыять кенә түгел, ә сәяси фирка тәшкил итәргә тиеш, дип раслыйлар.

4. Аять һәм хәдисләрдән тыш, фикыһ методологиясе, ягъни ысул әл-фикыһ төшенчәсе дә еш файдаланыла. Монда барыннан да элек "әл-вәҗиб" төшенчәсен әйтеп китәргә кирәк. Бу хәрәкәт әгъзалары гәп сатуны, мөэмин-мөселман кеше шәригать кануннары буенча яшәргә тиеш, дигән сүзләрдән башлыйлар. Бу табигый, әлбәттә. Ләкин, алар фикере буенча, шәригать кануннары үтәлсен өчен хәлифәт булуы зарур. Аннан соң алар, нинди дә булса бер постулат (исбат ителмичә нигез итеп алынган фикер) "вәҗиб" гамәлләр категориясенә туры килә икән, аңа китерүче башка гамәлләр дә шулай ук вәҗиб гамәлләр, дип аңлаталар. Ләкин бу һәрвакытта да алай түгел. Гади бер мисал китерик: әгәр дә кеше бай икән, ул зәкят түләргә тиеш, бу аның өчен мәҗбүри эш - вәҗиб. Әмма кешегә бай булу - мәҗбүри түгел, димәк, вәҗиб тә түгел.

5. Шуны истә тотарга кирәк: "Хизбүт-тәхрир" хәрәкәте оештырган митингларга аның әгъзалары үзләре бик йөрми. Килгән берничә кеше дә бу фирканең иң кечкенә бер өлеше вәкилләре булып чыга, алар бу вакытта үз җитәкчеләренең күрсәтмәләрен үтиләр. Мондый митингларда катнашучылар, кагыйдә буларак, илдә исламны эзәрлекләүләре турындагы шигарьләргә, мөселманнарны җәберләүләре турында интернетта таратылган чакыруларга ышанып, аларга теләктәшлек күрсәтергә чыккан гади кешеләр булалар. Ә аларның кайберләрен, бәлки, танышлары чакыргандыр. Һәм алар бу митингка мөселманнарның хәле өчен борчылып, аларның хәлен яхшыртырга ярдәм итәбез дип уйлап килгәннәрдер. Ниндидер бер чараның "Хизбүт-тәхрир" оештырганын каян белергә соң? Иң беренче чиратта, әлбәттә, Хизбның атрибутикасы - ислам шәһадәте язылган аклы-каралы байраклар. Бу байракларның мәгънәсендә, әлбәттә, бернинди дә начарлык юк, анда язылган юллар - һәр мөселман өчен изге. Ләкин бу фирка бүгенге көндә нәкъ менә шуннан файдалана да. Моннан тыш митинг булган урында өстендә шул ук байрак торган Җир шары сурәте булырга мөмкин. Чыгыш ясау һәм шигарьләр мондый чарада нәкъ менә сәясәт, дәүләт мәсьәләләренә кагыла һәм шуның нәтиҗәсендә хәлифәт мәсьәләләренә барып тоташа.

Islam-Today

Россия ислам институты ГАРӘП ТЕЛЕ КУРСЛАРЫНА ЧАКЫРА

Дәресләрдә телгә өйрәтү һәрьяклап алып барылачак:

- уку,
- текстлар тыңлау,
- язу,
- сөйләшү.

Дәресләр атнага 2 тапкыр үткәрелә.

Курс 45 дәрескә (90 академик сәгатькә каралган).

Тулы курс өчен 4 мең сумны алдан түләргә кирәк.

Кофе-брейк - бушлай!

Адрес: **Казан шәһәре, Газовая ур., 19 нчы йорт, "Ипподром" тукталышы (7, 26, 27, 31, 37, 59, 69, 69 а, 70, 74, 74 а, 77, 85 нче маршрут автобуслары, 6, 12 нче маршрут троллейбуслары).**

Курсларга дүшәмбе - җомга көннәрендә 13.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр 8-9047614887 телефонына (Айгөл Рафисовнага) шалтыратып язылырга мөмкин.

"ТАЯН АЛЛАГА"

Әдәби сүз, иҗат аша исламдагы югары рухый кыйммәтләргә игътибар юнәлтү, мөселманнар тормышын, динебез кыйммәтләрен әдәби әсәрләрдә яктырту һәм иманлы буын тәрбияләү ниятеннән Россия ислам институты Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, Татарстан Республикасы Милли китапханәсе белән берлектә "Таян Аллага" дүртенче әдәби конкурсын игълан итә.

Әсәрләрне җыю 2014 нче елның мартына кадәр дәвам итә.

Конкурста Татарстан һәм татарлар яши торган төбәкләрдән һәрбер теләгән кеше катнаша ала. Әсәрләр татар телендә электрон вариантта кабул ителә. Конкурс өч номинациядә үтә: шигърият, чәчмә әсәрләр, драматургия. Аз күләмле әсәрләр (шигырьләр, кыска хикәяләр h.б.) өчтән дә ким булмаска тиеш.

Һәр номинациядә беренче, икенче, өченче урыннар һәм гран-при билгеләнә.

Конкурс нәтиҗәләре буенча «Таян Аллага» исемле җыентык чыгарыла. Ул конкурска килгән иң яхшы әсәрләрдән туплана.

Оештыру комитеты адресы: **Казан ш., Газовая урамы, 19 нчы йорт, 312 каб.; тел.: (843) 277-58-12, 238-17-61; e-mail: tayanallaga@yandex.ru**

Хөрмә - Җәннәт Җимеше

Хәзерге медицина Коръәндә искә алынган җимешләрнең күп кенә авыруларны дәвалавын таный. Хөрмә җимеше һәм хөрмә агачы, мәсәлән, Коръәндә 20 тапкыр искә алына.

Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булса иде) болай дип әйткән: "Хөрмә - җәннәт җимешедер. Аның агуланудан шифалы сыйфаты бар" (Тирмизи: Тыйбб, 22); "Иртән ач карынга хөрмә җимеше ашагыз, аның ашказаны кортларын үтерә торган сыйфаты бар" (Канзел-Өммәл, X, 26).

Хөрмә физик һәм акыл үсешенә ярдәм итә. Ул бик туклыклы һәм рак авыруы барлыкка килүен кисәтә. Акыл эшчәнлеге аруын ала. Авырлы хатыннарга һәм бала имезүче аналарга бик файдалы. Тамак төбе авыруларын, бронхитны дәвалый.

Хөрмә җимешләр арасында аеруча туклыклысы. Хөрмә согы кан эшләп чыгаруга булыша. Хөрмәне зур булмаган микъдарларда куллану - шифа, ә туклану өчен күбрәк микъдарда да ашарга ярый. Аның елан һәм чаяннар чагып, агуланган вакытта кулланылучы сортлары билгеле. Хөрмәдә организм өчен кирәкле барлык витаминнар һәм аксым бар. Аның составында булган шикәр файдалы һәм организм тарафыннан җиңел үзләштерелә.

УКЫРГА БЕЗГӘ КИЛЕГЕЗ

Уку йортының тулы исеме	Лицензия номеры	Юнәлеш исеме	Квалификация (хәзерлек дәрәҗәсе) (лицензия буенча!)	Укыту формасы уку сроклары	Кабул итү имтиханнары	Кирәкле документлар	Кабул итү комиссиясенең телефон номеры; электрон почтасы; интернеттагы (рәсми) сайты; уку йорты адресы
Дәүләти булмаган уку йорты – "Россия ислам институты" – югары һөнәри белем бирү учреждениесе	№ 0142 (2010 нчы елның 9 нчы сентябреннән)	48.03.01 – Теология	Академик бакалавр	Уку йортына йөреп уку, 4 ел Читтән торып уку, 5 ел	Рус теле, тарих, җәмгыять белеме	Паспорт копиясе; кабул итү турында гариза; 3х4 үлчәмдә фоторәсем (8 данә); белем алу турында документ (оригиналы яки нотариуста раслатылган күчермәсе); анкета; 086/У формасы буенча медицина белешмәсе	+7 (843) 251-01-55; ucheb.otdel_riu@mail.ru; http://www.kazanriu.ru/; 420049 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Газовая урамы, 19 нчы йорт, 312 нче кабинет. Эш сәгатьләре: дүшәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе – иртәнге тугыздан (9.00) көндезге дүрткә (16.00) кадәр; сишәмбе, җомга – көндезге икедән (14.00) көндезге дүрткә (16.00) кадәр. РИИга укырга керү өчен документлар кабул ителү 20 нче июньнән башлана.
		48.04.01 – Теология	Магистр	Уку йортына йөреп уку, 2 ел Читтән торып уку, 3 ел	Инглиз теле, гарәп теле, дин тоту хокукы, дини философия		
		45.03.02 – Лингвистика, профиль: Чит телләр һәм мәдәниятләр укыту теориясе һәм практикасы	Академик бакалавр	Уку йортына йөреп уку, 4 ел Читтән торып уку, 5 ел	Рус теле, чит тел, тарих		
		38.03.01 – Икътисад, профиль: Бөтендөнья икътисады	Академик бакалавр	Уку йортына йөреп уку, 4 ел Читтән торып уку, 5 ел	Рус теле, математика, җәмгыять белеме		
		42.03.02 – Журналистика, профиль: массакүләм мәгълүмат чаралары (ислам журналистикасы)	Академик бакалавр	Уку йортына йөреп уку, 4 ел Читтән торып уку, 5 ел	Рус теле, әдәбият, җәмгыять белеме		
Казан ислам университеты	№ 1488 (2011 нче елның 7 нче июленнән)	Ислам дине белән бәйле дини персоналлар һәм фидакярләр хәзерләү	Бакалавр	Уку йортына йөреп уку, 4 ел Уку йортына йөреп уку-читтән торып уку (кичке уку), 5 ел Читтән торып уку, 5 ел	Ислам нигезләре (Коръән – 30 нчы өлешен күңелдән уку, ислам гакыйдәсе, ислам фикъһе, ислам әхлагы); гарәп теле, рус теле	Паспорт копиясе; кабул итү турында гариза; 3х4 үлчәмдә фоторәсем (8 данә); белем алу турында документ (оригиналы яки нотариуста раслатылган күчермәсе); анкета; 086/У формасы буенча медицина белешмәсе	+7 (843) 251-01-55; ucheb.otdel_riu@mail.ru; http://www.kazanriu.ru/; http://www.islam-portal.ru/; 420049 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Газовая урамы, 19 нчы йорт, 312 нче кабинет. Эш сәгатьләре: дүшәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе – иртәнге тугыздан (9.00) көндезге дүрткә (16.00) кадәр; сишәмбе, җомга – көндезге икедән (14.00) көндезге дүрткә (16.00) кадәр. КИУга укырга керү өчен документлар кабул ителү 20 нче июньнән башлана.
Мөселман дини оешмасы – Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең урта һөнәри дини белем бирү учреждениесе – "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе	Серия номеры 16 Л01 № 0000 513 (2013 нче елның 14 нче мартыннан)	Дин әһелләре һәм мөселман дине белән бәйле дини оешмаларга хезмәткәрләр хәзерләү	Имам-хатыйб, ислам нигезләре һәм гарәп теле мөгаллиме. Мөгаллим һәм гарәп теле тәрҗемәчесе	Уку йортына йөреп уку, 5 ел Читтән торып уку, 4 ел	Россия тарихы; рус теле; ислам нигезләре	Паспорт копиясе; кабул итү турында гариза; 3х4 үлчәмдә фоторәсем (4 данә); белем алу турында документ (оригиналы яки нотариуста раслатылган күчермәсе); анкета; 086/У формасы буенча медицина белешмәсе	+7 (843) 293-17-06 muhammadia@mail.ru http://muhammadiya.ru/; 420021 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 34 нче йорт.
Мөселман дини оешмасы – Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең "Ислам кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе" урта һөнәри белем бирү учреждениесе	№ 4873 (2013 нче елның 15 нче мартыннан)	Дин әһелләре һәм мөселман дине белән бәйле дини оешмаларга хезмәткәрләр хәзерләү	Имам-хатыйб, ислам нигезләре һәм гарәп теле мөгаллиме	Уку йортына йөреп уку, 5 ел Читтән торып уку, кичке уку, 3 ел	Татар теле (диктант); тест үткәрү, әңгәмә	Паспорт копиясе; кабул итү турында гариза; 3х4 үлчәмдә фоторәсем (4 данә); белем алу турында документ (оригиналы яки нотариуста раслатылган күчермәсе); анкета; 086/У формасы буенча медицина белешмәсе	+7 (843) 278-31-96; kvmm1000@yandex.ru; интернетта рәсми сайт юк; 420108 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Мәҗит Гафури урамы, 67 нче йорт.

Дин вә Мәгыйшәт

Февраль саны, № 2 (223)

Баш мөхәррир: Нияз САБИРҖАНОВ
Мөхәррир: Нәүбәһар КӘБИРОВА
Дизайнер: Фәнис Мотыйгуллин
Корректор: Айгөл КРОХИНА
Газета логотибы **хәттат** Рамил НАСЫЙБУЛЛОВ тарафыннан эшләнде

Гамәлгә куючы: Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27) .*

Редакция советы:
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе ***Камил СӘМИГУЛЛИН****;*
"Хузур" нәшрият йорты директоры ***Ришат ХӘМИДУЛЛИН****;*
Татарстан мөфтие урынбасары ***Нияз САБИРОВ****;*
Татарстанның баш казые ***Җәлил ФАЗЛЫЕВ****;*
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы рәисе ***Габдулла ӘДҺӘМОВ****.*

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
Электрон адрес: niyaz-kazan@yandex.ru
Телефон: +7 (843) 267-29-67.

Язылу индексы: 16046
Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин.

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).
Заказ № 09608
Тираж: 10 мең данә
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя – 6 сум.
График буенча бу санга **24 нче февраль көнне 18.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде. **Кул куелды: 18.00 сәгатьтә.**